ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

24 октябрь 2018 ел

**КАРАР**

№ 6345

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күп фатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ санлы Законы, Башкарма комитет Җитәкчесенең «Күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган турында» 2008 елның 8 апрелендәге 428 нче боерыгы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын (алга таба – административ регламент) кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү

өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлегенең эш регламентын раслау турында» 2009 елның 24 мартындагы 1125 нче карары;

2) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлегенең эш регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 30 декабрендәге 6313 нче карары;

3) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлегенең эш регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 4 июлендәге 3586 нчы карары;

4) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлегенең эш регламентын раслау турында» 2009 елның 24 мартындагы 1125 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 14 июнендәге 3551 нче карары;

5) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлегенең эш регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 5 декабрендәге 7569 нчы карары;

6) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлегенең эш регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 2 февралендәге 394 нче карары.

3. Күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага административ регламентны «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (parvo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 24 октябрендәге
6345 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын
өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге административ регламент Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ процедураларның (гамәлләрнең) срокларын һәм эзлеклелеген (алга таба – дәүләт функциясе), шулай ук дәүләт функциясен үтәгәндә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар белән эшчәнлек тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт функциясен үтәү күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге (алга таба – Бүлек) аша Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Дәүләт функциясен үтәү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы);

2) Россия Федерациясе торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы);

3) «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 214-ФЗ санлы Федераль закон);

4) «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ санлы Федераль закон);

5) «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ санлы Федераль закон);

6) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүчеләрнең өлешләп төзүдә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында кварталлык хисап хакында» 2005 елның 27 октябрендәге 645 нче карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 645 нче карары);

7) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативлары турында» 2006 елның 21 апрелендәге 233 нче карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 233 нче карары);

8) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы рәвештә тикшерүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 нчы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 нчы Карары);

9) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан карамагында әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яки оешмалардан тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүмат исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р санлы боерыгы (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 724-р санлы боерыгы);

10) Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күп фатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ санлы Законы

11) Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда физик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче приказы (алга таба – РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче приказы);

12) Финанс базарлары буенча Федераль хезмәтнең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативларын исәпләү тәртибе турында инструкцияне раслау хакында» 2006 елның 30 ноябрендәге 06-137/пз-н санлы приказы;

13) Финанс базарлары буенча Федераль хезмәтнең «Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрнең кварталлык хисап формаларын тутыру буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2006 елның 12 гыйнварындагы 06-2/пз-н санлы приказы (алга таба – Финанс базарлары буенча Федераль хезмәтнең 06-2/пз-н санлы приказы);

14) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган күпфатирлы йортка һәм (яки) башка күчемсез милек объектына карата мәгълүматны төзүченең рәсми сайтында урнаштыру тәртибенә таләпләрне раслау турында» 2016 елның 9 декабрендәге 914/пр санлы приказы (алга таба – РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 9 декабрендәге 914/пр санлы приказы);

15) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект декларациясе формасын раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр санлы приказы;

16) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 23.3 маддәсендә күрсәтелгән торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында төзүчеләр тарафыннан мәгълүмат урнаштыру тәртибе, составы, ысуллары, сроклары һәм периодик рәвештә кабатлануы турында нигезнамәне раслау турында» 2018 елның 11 маендагы 275/пр санлы приказы (алга таба – РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 11 маендагы 275/пр санлы приказы);

17) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән шундый кооператив тарафыннан кооператив әгъзалары һәм башка затлар алдында үз йөкләмәләренең үтәлеше турында

хисап формасын һәм торак-төзелеш кооперативы тарафыннан әлеге хисапны күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органына бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 3 июлендәге 955/пр санлы приказы;

18) Башкарма комитет Җитәкчесенең «Күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган турында» 2008 елның 8 апрелендәге 428 нче боерыгы (алга таба – Башкарма комитетның 428 нче боерыгы).

1.4. Күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге), Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм үткәрүгә карата таләпләрне исәпкә алып, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә контрольдә тотучы орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.5. Күп фатирлы торак йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) (алга таба – өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге)) предметы булып күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затларның (алга таба – төзүчеләрнең) күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләрне) үтәве тора.

1.6. Әлеге административ регламентны үтәү максатлары өчен төзүче дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) өлешләп төзү объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленә кадәр алынган очракта:

төзүче – оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, милкендә яки аренда хокукында, субаренда хокукында яисә «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль закон), Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 маддәсенең 2 пунктындагы 15 пунктчасында каралган очракларда түләүсез файдалану хокукындагы җир участогы булган һәм төзелеш өчен алынган рөхсәт нигезендә әлеге җир участогында, җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, күп фатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен 214-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче юридик зат;

2) өлешләп төзү объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленнән соң алынган очракта:

төзүче – хуҗалык җәмгыяте:

төзүче, (яки) техник заказчы сыйфатында һәм (яки) генераль подрядчы сыйфатында төзелеш подрядының килешүе нигезендә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә шундый күп фатирлы йортларны файдалануга тапшыруга алынган рөхсәтләре булган очракта, барлыгы гомуми мәйданы ун мең квадрат метрдан ким булмаган күп фатирлы йортларны төзүдә (булдыруда) катнашу тәҗрибәсе булган (өч елдан да ким булмаган) төп җәмгыять яисә төп җәмгыятьнең теләсә кайсы бүлендек хуҗалык җәмгыятьләре;

милкендә яки аренда хокукында, субаренда хокукында яисә 161-ФЗ номерлы Федераль законда, РФ Җир кодексының 39.10 маддәсенең 2 пунктындагы 15 пунктчасында каралган очракларда түләүсез файдалану хокукындагы җир участогы булган һәм төзелеш өчен алынган рөхсәт нигезендә әлеге җир участогында, җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, күп фатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен 214-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче;

исемендә «махсуслаштырылган төзүче» сүзләре булган.

1.7. Төзүче җир участогының шәһәр төзелеше планы яки территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә, күрсәтелгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүне (булдыруны) төзелешкә бер рөхсәт чикләрендә яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә, яисә төзелгән территорияне үстерү турында килешү төзелгән территория яки территорияне комплексны үзләштерү турында килешү яки территорияне комплекслы үстерү турында килешү төзелгән (алга таба – төзелешкә берничә рөхсәт) территория чикләрендә урнашкан бер яки берничә җир участогында төзелешкә бер яки берничә рөхсәт чикләрендә гамәлгә ашыру шарты белән проект документлары нигезендә, составына өлешләп төзү объектлары керә торган бер яки берничә күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итәргә хокуклы.

Өлешләп төзү объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленнән соң алынган очракта, төзүче төзелеп беткән территорияне үстерү турында берничә килешү һәм (яки) территорияне комплекслы үстерү турында килешүләр буенча бер үк вакытта эшчәнлек алып барырга хокуклы түгел.

1.8. Төзүче өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзелешкә бер яки берничә рөхсәт чикләрендә күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзүне (булдыруны) гамәлгә ашырырга хокуклы:

1) 214-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә, торак бүлмәне тапшыруны күздә тота торган өлешләп төзүдә катнашу килешүен дәүләт теркәвенә алганчы, күрсәтелгән акчаларны инвестицияләү хисабына сатып алынган мөлкәтне һәм күрсәтелгән чигерүләр (взнослар) хисабына формалаштырыла торган компенсация фондына түләү буенча чигерүләрне (взносларны) түләү буенча йөкләмләрне үтәү шарты белән;

2) 214-ФЗ санлы Федераль законның 15.4 маддәсендә каралган тәртиптә, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын эскроу счетларына урнаштыру шарты белән.

1.9. Төзүче, аңа күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт бирелгән моменттан башлап, күп фатирлы йортта һәм (яки) башка күчемсез милек объектындагы торак булмаган бүлмәләрне, машина кую урыннарын сатуны һәм арендага бирүне гамәлгә ашырырга, күрсәтелгән күчемсез милек объектларын карап тотуны, шул исәптән торак бүлмәләр һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

1.10. Төзүчеләр дәүләт функциясен үтәү кысаларында түбәндәгеләргә хокуклы:

1) күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә контрольне һәм күзәтчелекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең һәм ТР Министрлар Кабинетының норматив актлары белән билгеләнгән мәгълүматларны һәм (яки) документларны тапшырырга;

2) квартал саен күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп

итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзүче тарафыннан төзелеш проектларын, килешүләр буенча үз йөкләмәләрен гамәлгә ашыруның якынча графикларының үтәлеше турында хисап, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисап тапшырырга;

3) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән финанс тотрыклылыгы нормативларын үтәргә;

4) торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында 214-ФЗ санлы Федераль закон белән каралган мәгълүматны, шулай ук әлеге Федераль закон нигезендә күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзү (булдыру) гамәлгә ашырыла торган җир участогына хокук билгеләүче документларны урнаштырырга;

5) Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән күрсәтмәләрдә күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү.

1.11. Контроль органы тарафыннан дәүләт функциясе гамәлгә ашырылганда төзүчеләр түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт функциясен үтәү тәртибе турында аңлатмалар алырга:

2) Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирергә;

3) ведомствоара мәгълүмати эшчәнлек кысаларында, шулай ук башка дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә буйсынуындагы оешмалардан алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга.

1.12. Дәүләт функциясен үтәгәндә Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) төзүче тарафыннан 214-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен, килешү буенча өлешләп төзүдә катнашучылар тарафыннан түләнә торган акчаларны максатчан файдалануны контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

2) төзүче тарафыннан 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә төзүчегә карата билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

3) төзүче тарафыннан 214-ФЗ санлы Федераль законның 3.1 маддәсендә билгеләнгән мәгълүматны ачу һәм урнаштыруга карата таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

төзүче тарафыннан төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графиклары һәм килешүләр буенча үз йөкләмәләре үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырырыга;

4) төзүче тарафыннан 214-ФЗ санлы Федераль законның 18 маддәсенең 1.2 бүлегендә өлешләп төзүдә катнашучылар тарафыннан түләнә торган акчаларның исәбен алып баруга карата билгеләнгән таләпләр үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

5) төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә яисә шундый бәяләмәне бирүдән дәлилләнгән баш тарту;

6) төзүчедән, ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат – төзүче белән эш итә торган (капиталда 25 проценттан артык өстенлек итүче катнаш булган) физик зат турында мәгълүмат алырга;

7) күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләти җайга салуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы (алга таба – вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы) тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокта төзүчедән, юридик затның тулы

исемен яки шәхси эшмәкәрнең фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), адресын (урнашу урынын) күрсәтеп, инженерлык эзләнүләрен, архитектура-төзелеш проектлаштыруны үткәрү һәм төзелеш буенча эшләрне, товарлар белән тәэмин итүне һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы затлар турында, шулай ук мондый товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтү төрләре һәм, Россия Федерациясе законнарында әлеге рөхсәтләрнең (лицензияләрнең) булуы турында таләп каралган очракта, әлеге затларның күрсәтелгән эш, товар белән тәэмин итү һәм хезмәт күрсәтү төрләрен гамәлгә ашыруга тиешле рөхсәтләре (лицензияләре) булу турында мәгълүмат алырга;

8) рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру буенча функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органыннан төзүчеләрнең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны алырга;

9) салымнар һәм җыемнар турында законнар үтәлешен контрольдә тоту һәм күзәтчелек итү буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә (андагы белешмәләрне), 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсендәге 2 бүлекнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләрнең төзүче тарафыннан үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга;

10) эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсендәге 2 бүлекнең 8 пунктында билгеләнгән таләпләрнең төзүче тарафыннан үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 116.1 маддәсенең 1 пунктында билгеләрнең таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны алырга;

11) дәүләт кадастр исәбен, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрын алып баруны һәм Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы мәгълүматларны бирүне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан һәм аның территориаль органнарыннан төзүчеләрнең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга;

12) төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затлардан «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 маддәсендә билгеләнгән срокта,

күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган мәгълүматларны һәм (яки) документларны алырга;

13) төзүчеләрдән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзүче тарафыннан төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графиклары, килешүләр буенча йөкләмәләренең үтәлеше турында кварталлык хисап, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын алырга;

14) торак-төзелеш кооперативыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә, торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән шундый кооператив тарафыннан кооператив әгъзалары һәм башка затлар алдында үз йөкләмәләренең үтәлеше турында кварталлык хисап, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын алырга;

15) төзүчеләрнең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотарга;

16) Федераль закон таләпләренең үтәлешен контрольдә тотарга, шул исәптән Россия Федерациясе Үзәк банкына, төзүче белән җаваплылыкны үз өстенә алу килешүе төзегән банкның яки төзүче белән иминият килешүе төзегән иминият оешмасының 214-ФЗ санлы Федераль закон таләпләренә туры килүе турында мәгълүмат бирү хакында запрослар җибәрергә, шулай ук гражданнарның һәм юридик затларның 214-ФЗ санлы Федераль законны бозуга бәйле шикаятьләрен карап тикшерергә;

17) күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затларга Федераль закон таләпләрен, шулай ук күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән башка таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр җибәрергә һәм шундый кимчелекләрне бетерү срокларын билгеләргә;

18) Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында http://nabchelny.ru/, карау мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән чикләнгән мәгълүматлардан тыш, төзүче, торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә үткәрелгән тикшерүләр турында мәгълүмат урнаштырырга, шулай ук 214-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен бозган өчен төзүчене, аның вазыйфаи затларын җаваплылыкка тарту турында законлы көченә кергән карарлар турында мәгълүматлар, Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен һәм законнарда билгеләнгән таләпләрне бозган өчен торак-төзелеш кооперативын административ җаваплылыкка тарту турында мәгълүматлар урнаштырырга;

19) төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затларны (аларның вазыйфаи затларын), торак-төзелеш кооперативларын (аларның вазыйфаи затларын)

214-ФЗ санлы Федераль законда һәм Россия Федерациясе законнарыда билгеләнгән җаваплылыкка тарту өчен кирәкле чаралар күрергә;

20) өлешләп төзүдә катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук күп фатирлы йорт төзүдә үз акчалары белән катнашкан торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының Россия Федерациясе Торак кодексының 11 бүлегендә каралган хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча гаризалар белән судка мөрәҗәгать итәргә (шундый хокуклар һәм мәнфәгатьләр бозылган очракта);

21) җинаять эше кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен, җинаять җәзасы бирелә торган эшләр билгесе булган мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары ачыклануга бәйле материалларны хокук саклау органнарына җибәрергә;

22) вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан билгеләнгән критерийлар нигезендә, акчалары күп фатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнарны зыян күргән дип танырга һәм шундый гражданнар реестрын алып барырга;

23) төзүченең күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыруны билгеле срокка туктату турындагы гариза белән яисә 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсенең 15 һәм 16 бүлекләрендә билгеләнгән очракларда, төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затларны ликвидацияләү турындагы гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә;

24) төзүчеләрнең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тоту турында Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеген җайга салучы федераль законнар нигезендә шундый кооперативлар тарафыннан күп фатирлы йортлар төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүне контрольдә тотуны (күзәтчелекне) гамәлгә ашырырга;

25) торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 маддәсенең 1 бүлегендә алар тарафыннан мәгълүмат һәм документлар урнаштыруга карата билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

26) Россия Федерациясе Торак кодексының 123.2 маддәсенең 4 бүлеге нигезендә, торак-төзелеш кооперативының күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшерүне гамәлгә ашырырга;

27) торак-төзелеш кооперативыннан һәм кооператив белән күп фатирлы йорт төзүгә бәйле килешүләр төзегән башка затлардан «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 маддәсендә билгеләнгән срокта, торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган документларны һәм мәгълүматны алырга;

28) торак-төзелеш кооперативының идарә органнарыннан ачыкланган кимчелекләрне бетерүне таләп итәргә;

29) гражданнарның һәм юридик затларның торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 110 маддәсенең 3 бүлегендәге

(киләчәктә күп фатирлы йортны карап тотудан тыш) һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 маддәсендәге таләпләр бозылуга бәйле шикаятьләрен карап тикшерергә;

30) торак-төзелеш кооперативына Россия Федерациясе Торак кодексының 110 маддәсенең 3 бүлегендәге (киләчәктә күп фатирлы йортны карап тотудан тыш) һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 маддәсендәге таләпләрне бозуларны бетерү турында үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр җибәрергә һәм мондый кимчелекләрне бетерү срокларын билгеләргә;

31) ачыкланган кимчелекләрне бетерү турындагы күрсәтмә билгеләнгән срокта торак-төзелеш кооперативы тарафыннан үтәлмәгән очракта, шулай ук әлеге кимчелекләр торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә реаль куркыныч тудырган очракта, торак-төзелеш кооперативы тарафыннан тиешле кимчелекләр бетерелгәнгә кадәр, кооперативның яңа әгъзаларын җәлеп итү буенча торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген туктату турында күрсәтмәләр чыгарырга, әлеге кооператив тарафыннан күрсәтмәләр үтәлмәгән очракта торак-төзелеш кооперативын ликвидацияләү турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать итәргә;

32) торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасыннан торак-төзелеш кооперативы әгъзалары реестрындагы мәгълүматларны, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 маддәсендә каралган башка мәгълүматны алырга;

33) 214-ФЗ санлы Федераль законның 23.3 маддәсенең 5 бүлегендә күрсәтелгән мәгълүматны торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында урнаштырырга;

34) дәүләт кадастр исәбен, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрын алып баруны һәм Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы мәгълүматларны бирүне гамәлгә ашыручы органга түбәндәгеләр турында белдерү кәгазе җибәрергә:

- төзүченең күп фатирлы йортлар төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итәргә хокукы булмау турында – төзүченең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 бүлегендә, 2 бүлегендәге 1, 1.2-1.7, 2 пунктларда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү һәм (яки) төзүче тарафыннан акчаларны 214-ФЗ санлы Федераль законның 18 маддәсендә каралмаган максатларда файдалану факты билгеләнгән көннән соң килүче бер эш көне эчендә;

- төзүченең күп фатирлы йортлар төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итәргә хокукы булмау турында - төзүченең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендәге 1.1, 1.8, 7 һәм 8 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү факты билгеләнү турында, төзүченең әлеге пунктта каралган таләпләргә туры килмәү факты билгеләнгән көннән башлап өч эш көненнән соңга калмый төзүченең шәхси кабинетына җибәрелә торган хәбәр төзүченең шәхси кабинетына җибәрелгән көннән башлап биш эш көненнән ким һәм җиде эш көненнән соң булмаган срокта;

- төзүче тарафыннан теркәлгән өлешләп төзүдә катнашу килешүе буенча өлешләп төзү объектын өлешләп төзүдә катнашучыга тапшыру буенча бурычлар үтәлмәү турында – шундый бурыч җиткән көннән башлап алты ай эчендә;

- төзүченең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1.1 һәм 2 бүлекләрендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында – төзүченең күрсәтелгән таләпләргә туры килү факты билгеләнгән көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмый.

1.13. Дәүләт функциясен үтәгәндә Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендә вәкаләтләнгән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органыннан төзүченең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны, шулай ук торак-төзелеш кооперативының күп фатирлы йортлар төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны (шул исәптән күп фатирлы йорт төзүгә бәйле документларны) сорарга һәм алырга;

2) расланган нормативлар белән чагыштырганда финанс елы дәвамында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен чыгымнарның көтелгән күләме үзгәргән очракта, тиешле нормативны ачыклау өлешендә Татарстан Республикасы бюджетын төзү һәм үтәү вәкаләтләренә ия органга нигезле тәкъдимнәр җибәрергә;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча мәгълүмати, консультация, оештыру һәм методик ярдәм алырга;

4) муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен үзенең материаль ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга;

5) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча актлар чыгарырга.

1.14. Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәсе булып, төзүчеләр тарафыннан күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә закон таләпләре үтәлешен тикшерү һәм хокук бозулар ачыкланган очракта, аларны кисәтүгә һәм (яки) мондый хокук бозу нәтиҗәләрен бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрү, шул исәптән аларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту тора.

Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

- төзүченең кварталлык хисабын тикшерү актын төзү (административ регламентка 2 нче кушымта);

- төзүче тарафыннан торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында мәгълүмат ачуга карата таләпләр үтәлешен тикшерү актын төзү (административ регламентка 3 нче кушымта);

- Бүлек тарафыннан планлы һәм планнан тыш тикшерү акты төзү;

- төзүченең күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә РФ законнарын бозуларны бетерү турында күрсәтмә төзү (административ регламентка 4 нче кушымта);

- төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү (алга таба - бәяләмә) яисә Башкарма комитет тарафыннан расланган Административ регламент нигезендә нигезле баш тарту;

- акчалары күп фатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданны зыян күрүче дип тану яки Башкарма комитет тарафыннан раслаган административ регламент нигезендә нигезле баш тарту.

Федераль законда башкача билгеләнмәгән очракта, мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына керүче аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә зыян китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш

хәлләр килеп чыгуга китерү яисә күрсәтелгән нәтиҗәләргә куркыныч тудыру турында расланган мәгълүматлар булмаган һәм юридик зат элек тиешле таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаган очракларда, Бүлектә юридик затлар белән үзара бәйләнешсез гамәлгә ашырылган контроль чараларын тормышка ашыру барышында алынган яисә дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүматта, мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш) әзерләнүче хокук бозулар турында яки хокук бозу билгеләре турында мәгълүматлар булганда, Бүлек юридик затны мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтә һәм юридик затка мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу турыда мондый кисәтүдә билгеләнгән срокта Бүлеккә хәбәр итәргә тәкъдим итә.

1.15. Юридик затлар белән үзара бәйләнешсез контроль чараларын оештыру һәм үткәрү.

1.15.1. Юридик затлар белән үзара бәйләнешсез контроль чаралары, шундый чараларны үткәрүгә Бүлек җитәкчесе тарафыннан раслана торган йөкләмәләр нигезендә, үз компетенцияләре чикләрендә Бүлекнең вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелә.

1.15.2. Үткәргәндә Бүлекнең юридик затлар белән үзара бәйләнеше таләп ителми торган контроль чараларга (алга таба – юридик затлар белән үзара бәйләнешсез контроль чаралары) түбәндәгеләр керә:

1) «Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырганда мәҗбүри таләпләр үтәлешен күзәтү;

2) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә, юридик затның эшчәнлеге яисә гамәлләре турында мондый затлар тарафыннан (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалану юлы белән) Бүлеккә тапшырыла торган яки Федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралмаган бурычларны юридик затларга йөкләмичә Бүлек тарафыннан алынырга мөмкин булган (шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында) мәгълүматны анализлау юлы белән мәҗбүри таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үтәлешен күзәтү.

1.15.3. 294-ФЗ санлы Федераль законның 8.3 маддәсенең 1 бүлегендә күрсәтелгән контроль чараларны үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу ачыкланган очракта, Бүлекнең вазыйфаи затлары үз компетенциясе чикләрендә мондый хокук бозуларны булдырмау буенча чаралар күрәләр, шулай ук, кирәк булганда 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсендәге 2 бүлекнең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затларны планнан тыш тикшерүне билгеләү турында карар кабул итү өчен, язма рәвештә ачыкланган кимчелекләр турындагы мәгълүматны үз эченә алган дәлилләнгән күрсәтмәне Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

1.15.4. 294-ФЗ санлы Федераль законның 8.2 маддәсенең 5-7 бүлекләрендә күрсәтелгән юридик затлар белән үзара бәйләнешсез контроль чараларын үткәрү барышында әзерләнүче хокук бозулар яки мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу билгеләре турында мәгълүматлар алынган очракта, Бүлек юридик затка мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү җибәрә.

## 2 бүлек. Дәүләт функциясен үтәү тәртибенә таләпләр

2.1. Дәүләт функциясен үтәү турында мәгълүмат бирү тәртибе

2.1.1. Дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан дәүләт функциясен үтәү тәртибе турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) Интернет челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында (http://nabchelny.ru/) урнаштырып;

3) Башкарма комитетка (Бүлеккә) шәхсән яки телефон аша телдән мөрәҗәгать итеп;

4) электрон документ формалаштырганда – кәгазьдә почта аша, шул исәптән электрон рәвештә Бүлекнең электрон почтасы goscontrol@list.ru аша.

2.1.2. Бүлекнең урнашу урыны: 423805, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 109 кабинет.

2.1.3. Бүлекнең эш графигы:

- дүшәмбе - җомга: 8-00 дән 17-00 кадәр;
- төшке аш вакыты: 12-00 дән 13-00 кадәр;
- ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

Дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча кабул итү көннәре:

- өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле бүлеге башлыгы – һәр сишәмбе 16-00 сәгатьтән 18-00 сәгатькә кадәр.
- өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле бүлеге – һәр чәршәмбе 15-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр.

2.1.4. Бүлекнең белешмә телефоннары:

(8552) 30-56-80 и (8552) 30-56-81.

2.1.5. Дәүләт функциясен үтәү түләүсез нигездә гамәлгә ашырыла. Дәүләт функциясен үтәү кысаларында дәүләт функциясен яисә аерым административ процедураларны башкарган өчен Россия Федерациясе законнарында түләү каралмаган.

2.1.6. Дәүләт функциясен үтәү срогы түбәндәгечә тәшкил итә:

1) кварталлык хисапны тикшерү – төзүченең хисабы кергән көннән башлап 60 эш көне;

2) 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 һәм 12 маддәләрендә каралган планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне үткәрү – 20 көн;

3) төзүчеләр тарафыннан торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында мәгълүмат ачуга һәм урнаштыруга карата билгеләнгән таләпләрне тикшерү – 20 эш көне;

4) торак-төзелеш кооперативының күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен гамәлгә ашыру – 20 эш көне;

5) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 12 августындагы 560 нчы приказы таләпләре кысаларында, акчалары күп фатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнарны зыян күрүчеләр дип тану һәм шундый гражданнар реестрын алып бару – 14 эш көне;

6) төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү яисә шундый бәяләмә бирүне кире кагу – 30 календарь көн.

2.1.7. Кварталлык хисапны тикшерү, төзүчеләрнең өлешләп төзүдә катнашучылар тарафыннан түләнә торган акчалардан максатчан файдалануын

тикшерү өлешендә дәүләт функциясен үтәү срогы төзүче тарафыннан соратып алына торган документларны бирү өчен кирәкле срокка озайтылырга мөмкин, ләкин 10 эш көненнән дә артырга тиеш түгел.

2.1.8. Дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору күздә тотылмый.

2.2. Тикшерүләрне үткәрү (планлы тикшерүләр, планнан тыш тикшерүләр) өчен нигезләр:

2.2.1. Планлы тикшерүләр Бүлек вәкаләтләре нигезендә, аның тарафыннан эшләнә һәм раслана торган еллык планнар (алга таба – план) буенча үткәрелә.

Планлы тикшерү предметы булып юридик затның эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында 214-ФЗ санлы Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәве тора.

Яр Чаллы шәһәренең төзелеш алып барыла торган территориясендә төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затка төзелешкә рөхсәт бирү датасыннан башлап яисә шундый затны соңгы тапкыр планлы тикшерү тәмамланган датадан башлап бер ел узу планлы тикшерүне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертү өчен нигез булып тора.

294-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә План түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга мөмкин:

1) эшчәнлекләре планлы рәвештә тикшерелергә тиешле юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) исеме, юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу урыны;

2) һәр планлы тикшерү үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлы тикшерүне үткәрүнең башлану датасы һәм сроклары;

4) конкрет планлы тикшерүне гамәлгә ашыручы Бүлекнең исеме.

Бүлек, планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы елның 1 сентябренә кадәр, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Бүлекнең урнашу урыны буенча прокуратура органына җибәрә. Бүлек прокуратура органнарының тәкъдимнәрен карап тикшерә һәм аларны карау нәтиҗәләре буенча, планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы елның 1 ноябренә кадәр, планлы тикшерүләрнең расланган еллык планын прокуратура органнарына җибәрә.

Планлы тикшерүләрнең еллык планы Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан раслана.

Планлы тикшерүләрнең еллык планы кызыксынган затлар игътибарына аны рәсми сайтта www.nabchelny.ru урнаштыру юлы белән җиткерелә.

Ттикшерүләрнең еллык планына үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы рәвештә тикшерүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 нчы карары нормалары һәм таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Бүлек тарафыннан юридик затка планлы тикшерү үткәрү турында, ул үткәрелә башлаганчы өч эш көненнән дә соңга калмый, Бүлек җитәкчесенең планлы тикшерү үткәрелә башлау турындагы боерыгы күчермәсен почта аша аны тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат җибәреп һәм (яки) әгәр мондый адрес бердәм дәүләт юридик затлар реестрында күрсәтелгән булса яисә элек юридик зат тарафыннан Бүлеккә бирелгән булса, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның электрон почта адресы буенча җибәрелгән электрон документ ярдәмендә яки башка уңайлы ысул белән хәбәр ителә.

Планлы тикшерү документар һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә. Планнан тыш тикшерү предметы булып юридик зат тарафыннан эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү, гражданнар тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына керүче аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зыян китерүне булдырмау буенча, дәүләт иминлеген тәэмин итү буенча, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү буенча, шундый зыян килү нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар үткәрү, Бүлек күрсәтмәләрен үтәү тора.

2.2.2. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әгәр күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан күрсәтмәдә күрсәтелгән кимчелекләр бетерелмәгән булса, күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан 214-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен, шулай ук күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез мөлкәт объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, вәкаләтле органның норматив хокукый актлары белән билгеләнгән башка таләпләрен бозуларны бетерү турында Бүлек тарафыннан бирелгән күрсәтмәне үтәү срогы чыгу;

2) төзүченең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында кварталлык хисабын, Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән бухгалтерлык хисабын (шул исәптән еллык) һәм (яки) проект декларациясен анализлауны үткәрү барышында күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыклану;

3) контрольдә тотучы органга 214-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, вәкаләтле органның норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органнарының актлары таләпләрен бозу фактлары турында гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, 214-ФЗ санлы Федераль законның 23.2 маддәсенең 1 бүлегендә күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмадан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән мәгълүмат керү;

3.1) төзүченең төзелеш проектын тормышка ашыру графигыннан алты һәм аннан күбрәк айга тайпылуы;

4) 214-ФЗ санлы Федераль законның һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив хокукый актларының мәҗбүри таләпләрен бозулар ачыкланан очракта, Бүлек җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) Россия Федерациясе Президентының яки Россия Федерациясе Хөкүмәтенең яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органының йөкләмәсе нигезендә чыккан планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы приказы (боерыгы);

5) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе;

6) Бүлеккә вәкаләтле банкның 214-ФЗ санлы Федераль законның 18.2 маддәсенең 4 бүлегендә каралган белдерү кәгазе керү.

Тиешле тикшерү башланганнан соң, аны оештыру өчен сәбәп булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланган яисә мөрәҗәгатькә яки гаризага күрәләтә дөрес булмаган мәгълүматлар кертелү билгеләнгән очракта, Бүлек җитәкчесенең карары буенча алдан тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатала.

Гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә күрәләтә ялган мәгълүматлар күрсәтелгән очракта, Бүлекнең гражданнан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән кергән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүгә бәйле чыгымнарын күрсәтелгән затлардан түләтү турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Планнан тыш тикшерү, 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 һәм 12 маддәләрендә билгеләнгән тәртиптә, документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

Документар тикшерүне (планлы һәм планнан тыш) оештыру 294-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла һәм Бүлекнең урнашу урыны буенча үткәрелә.

Юридик затларны планнан тыш күчмә тикшерү, 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсенең 12 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә кичекмәстән прокуратура органына хәбәр итеп, 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсендәге 11 бүлекнең 4 пунктында күрсәтелгән нигез буенча Бүлек тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

Бүлек җитәкчесенең юридик затны планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында боерыгы имзаланган көнне, Бүлек аны үткәрүне килешенү максатында, юридик затның эшчәнлеге гамәлгә ашырылу урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турында гаризаны (РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче приказы белән расланган типовой форма нигезендә рәсмиләштерелә) тапшыра яисә почта аша аны тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрә. Әлеге гаризага Бүлек җитәкчесенең планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерыгының күчермәсе һәм аны үткәрү өчен нигез булып торган мәгълүматларны үз эченә алган документлар теркәлә.

Прокурорның яки аның урынбасарының планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турында яки аны үткәрүне килешенүне кире кагу турында карары буенча югарыдагы прокурорга яки судка шикаять бирелергә мөмкин.

Төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затка 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсендәге 11 бүлекнең 4 пнктында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында алдан хәбәр итү рөхсәт ителми.

Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең юридик зат тарафыннан үтәлү срогы чыгу планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып торган очракта, мондый тикшерү предметы булып Бүлек тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше генә тора ала.

2.3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар – Бүлек башлыгы һәм Бүлекнең баш белгечләре.

2.4. Юридик затларның 294-ФЗ санлы Федераль законны бозган өчен җаваплылыгы.

Тикшерүләр үткәрүгә нигезсез тоткарлык ясый торган, тикшерүләр үткәрүдән качарга тырышкан һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне үтәүдә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында Бүлек күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәгән юридик затлар, юридик затларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы.

2.5. Тикшерү үткәргәндә Бүлекнең, аның җаваплы затларының җаваплылыгы.

Бүлек, аның вазыйфаи затлары, тикшерү үткәргәндә функцияләргә туры килгән вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокуксыз эш иткән (эш итмәгән) очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

Бүлек вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт бурычлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра, вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт бурычларының тиешенчә үтәлмәү очраклары исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшеренүләре үткәрә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата мондый чаралар күрелгән көннән башлап 10 көн эчендә, Бүлек хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка язма рәвештә күрелгән чаралар турында хәбәр җибәрергә тиеш.

## 3 бүлек. Юридик затларга куела торган мәҗбүри таләпләр

3.1. Юридик затларга куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Эшчәнлекнең төре | Мәҗбүри таләпләрнең формулировкасы | Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив хокукый актлар |
| --- | --- | --- |
| Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп күчемсез милек объектларын төзү | Өлешләп төзүдә катнашу килешүе нигезендә күп фатирлы йорт төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү хокукына түбәндәге таләпләргә җавап биргән төзүче ия:<br>- проект документлары һәм проект документларына экспертизаның уңай бәяләмәсе булу;<br>- төзүченең үз акчаларының күләме планлаштырылган төзелеш бәясенең кимендә ун процентын тәшкил итәргә тиеш;<br>- 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсенең 2 бүлегендә күрсәтелгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына 214-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсенең 2 бүлеге нигезендә проект декларациясен җибәрү датасына, төзүченең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2.3 бүлеге нигезендә вәкаләтле банкта ачылган банк счетында төзелешнең проект бәясенең кимендә ун проценты | 214-ФЗ санлы Федераль законның 3, 3.1 һәм 3.2 маддәләре;<br>2018 елның 1 июлендәге 175-ФЗ санлы Федераль закон;<br>2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ санлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | күләмендә акчасы булу яисә күрсәтелгән датага төзүченең вәкаләтле банк белән төзелгән һәм вәкаләтле банк тарафыннан төзүчегә составына өлешләп төзү объектлары керә торган күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекты төзү (булдыру) өчен, төзелешнең проект бәясенең кимендә кырык проценты күләмендә максатчан кредит бирүне күздә тоткан кредит килешүе булу;<br>- төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә (булдыруга) бәйле һәм өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле максатчан кредитлардан һәм (яки) мондый займ буенча процентлар займ килешүе төзү датасына гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының ике процент пунктка арттырылган төп ставкасыннан артмаган очракта, әлеге бүлектә каралган максатларга төзелеш өчен бирелгән рөхсәтләрнең һәркайсы буенча төзелешнең проект бәясенең егерме процентыннан артмаган күләмдә төзүченең төп җәмгыяте тарафыннан бирелгән максатчан займнардан тыш, кредитлар, займнар, ссудлар буенча йөкләмәләр булмау;<br>- төзүче тарафыннан, акцияләрдән тыш, кыйммәтле кәгазьләр чыгару яки бирү гамәлгә ашырылмау;<br>төзүченең төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә (булдыруга) һәм өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле булмаган йөкләмәләре 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсенең 2 бүлегендә күрсәтелгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына 214-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсенең 2 бүлеге нигезендә проект декларациясен җибәрү датасына төзелешнең проект бәясенең бер процентыннан артмый. Әлеге кагыйдә төзүченең 214-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсе нигезендә | |

| | | |
|---|---|---|
| | өлешләп төзү объектының җитешсезлекләрен бетерү буенча йөкләмәсенә карата кулланылмый;<br>- төзүче карамагында булган мөлкәт өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен, шулай ук төзүченең төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә (булдыруга) һәм өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле булмаган шәхси йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен файдаланылмый;<br>- өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү буенча йөкләмәләр булмау;<br>- финанс тотрыклылыгы нормативларын үтәү;<br>- төзүчегә карата юридик зат-төзүчене ликвидацияләү процедуралары үткәрелмәү;<br>- юридик зат-төзүчегә карата банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында арбитраж суды карары булмау;<br>- юридик зат-төзүчегә карата административ җәза чарасы буларак аның эшчәнлеген туктату турында арбитраж суды карары булмау;<br>- төзүче намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмау;<br>җир участогын сату буенча аукционның намуссыз катнашучылары реестрында булмау;<br>- юридик зат-төзүченең салымнар, җыемнар буенча түләнеп бетмәгән бурычлары, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау (салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә кичектерү, өлешләп түләү, инвестиция салым кредиты бирелгән суммалардан тыш);<br>- төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы зат, төзүченең коллегиаль башкарма органының әгъзасы булып торган зат яки ул төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма | |

| | | |
|---|---|---|
| | органы функцияләрен үтәгән очракта, идарәче компаниянең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы зат яисә төзүченең бер генә кеше идарә итә торган вакытлы органы (алга таба – төзүченең җитәкчесе), ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат-төзүче белән идарә итүче (капиталда биш проценттан артык катнашы булган) физик зат, төзүченең баш бухгалтеры 214-ФЗ санлы Федераль законның 3.2 маддәсендә билгеләнгән таләпләргә туры килә;<br>- төзүче тарафыннан 214-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсенең 2.1 бүлеге нигезендә өлешләп төзүнең беренче катнашучысы белән килешү төзегәнгә кадәр бирелгән төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә булу;<br>- һәр төзелеш объектына аерым счет ачу;<br>- 214-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә торак бүлмәне тапшыруны күздә тотучы өлешләп төзүдә катнашу килешүен дәүләт теркәвенә алганга кадәр, күрсәтелгән чигерүләр (взнослар) һәм күрсәтелгән акчаларны инвестицияләү хисабына сатып алынган мөлкәт хисабына формалаштырыла торган компенсация фондына (алга таба – компенсация фонды) чигерүләр (взнослар) түләү буенча бурычларын үтәү шарты белән, төзүче әлеге Федераль закон нигезендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) өч һәм аннан күбрәк блоктан торган торак йортларны өлешләп төзү өчен гражданнарның һәм юридик затларның акчаларын җәлеп итәргә хокуклы;<br>- төзүченең еллык бухгалтерлык (финанс) хисабы мәҗбүри аудитка алынырга тиеш. Төзүче түбәндәге хисап чорларына – беренче квартал, ярты еллык һәм тугыз ай өчен кварталлык хисап нигезендә арадаш бухгалтерлык (финанс) хисабы төзи. Төзүче 214-ФЗ санлы Федераль законның 3.1 маддәсенең 2 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, тиешле аралыктагы хисап чоры тәмамланганнан соң арадаш бухгалтерлык | |

| | | |
|---|---|---|
| | (финанс) хисабын һәм тиешле хисап чоры тәмамланганнан соң йөз егерме календарь көннән соңга калмый еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын һәм аудитор бәяләмәсен ача.<br><br>Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче төзүче түбәндәгеләргә бурычлы:<br><br>- Төзүче җир участогының шәһәр төзелеше планы яки территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә, күрсәтелгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүне (булдыруны) төзелешкә бер рөхсәт чикләрендә яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә, яисә төзелгән территорияне үстерү турында килешү төзелгән территория яки территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү яки территорияне комплекслы үстерү турында килешү төзелгән (алга таба – төзелешкә берничә рөхсәт) территория чикләрендә урнашкан бер яки берничә җир участогында төзелешкә бер яки берничә рөхсәт чикләрендә гамәлгә ашыру шарты белән проект документлары нигезендә, составына өлешләп төзү объектлары керә торган бер яки берничә күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итәргә. Төзүче төзелгән территорияне үстерү турында, һәм (яки) территорияне комплекслы үстерү турында, һәм (яки) территорияне комплекслы үзләштерү турында берничә килешү буенча бер үк вакытта эшчәнлекне гамәлгә ашырырга хокуксыз;<br>- өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, төзелешкә бер яки берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзүне (булдыруны) гамәлгә ашырырга:<br>1) 214-ФЗ санлы Федераль законның 4 бүлегендәге таләпләрне үтәү;<br>2) 214-ФЗ санлы Федераль законның | |

| | | |
|---|---|---|
| | 15.4 маддәсендә каралган тәртиптә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын эскроу счетларында урнаштыру.<br>214-ФЗ санлы Федераль законның 23.3 маддәсендә күрсәтелгән торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән аңа ирекле керү мөмкинлеген тәэмин итәргә (мәгълүматны ача).<br>- төзүченең коллегиаль башкарма органы, төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы яки төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашырган очракта, идарәче компания яисә төзүченең бер генә кеше идарә итә торган вакытлы органы (алга таба – төзүченең җитәкчесе), төзүченең баш бухгалтеры һәм күрсәтелгән вазыйфаларга кандидатлар 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсендә билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш;<br>- төзүче җитәкчесенең вәкаләтләре туктатылу турында, төзүченең яңа җитәкчесен сайлау (билгеләү) турында, шулай ук төзүченең бер генә кеше идарә итә торган вакытлы органын булдыру турында карарлар кабул ителгән моменттан башлап өч эш көненнән дә соңга калмый, төзүче бу хакта 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсенең 2 бүлегендә күрсәтелгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына хәбәр итәргә һәм күрсәтелгән затларның әлеге маддә таләпләренә туры килүе турында мәгълүмат бирергә тиеш.<br>- Төзүченең җитәкчесе яки төзүченең баш бухгалтеры булып түбәндәгеләр тора алмый:<br>1) икътисадый эшчәнлек өлкәсендә җинаятьләр яки дәүләт хакимиятенә каршы җинаятьләр өчен суд хөкеме туктатылмаган яки үтәлмәгән зат;<br>2) аны дисквалификация рәвешендәге административ җәзага дучар ителгән дип исәпләү срогы үтмәгән зат;<br>3) «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге | |

| | | |
|---|---|---|
| | 127-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә юридик зат йөкләмәләре буенча субсидиар җаваплылыкка һәм (яки) юридик заттан зыянны түләтү рәвешендәге җаваплылыкка тартылган зат, әгәр зат тарафыннан суд актында билгеләнгән бурычлар үтәлгән көннән башлап биш елдан ким вакыт узган булса;<br>4) 214-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсенең 2 бүлеге нигезендә 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсенең 2 бүлегендә күрсәтелгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына проект декларациясен җибәрү датасына кадәрге биш ел дәвамында юридик затның бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашырган һәм арбитраж суды тарафыннан зат бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип танылган зат;<br>5) 214-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсенең 2 бүлеге нигезендә 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсенең 2 бүлегендә күрсәтелгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына проект декларациясен җибәрү датасына кадәрге өч ел дәвамында турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) төзүченең биш процентттан артык акцияләренә (өлешләренә) ия булган һәм арбитраж суды тарафыннан зат бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип танылган зат.<br>4. Ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат-төзүчегә хуҗа булган (кпиталда биш проценттан артык катнашы булган) физик зат 214-ФЗ санлы Федераль законның 3.2 маддәсенең 3 бүлегендәге таләпләргә туры килергә тиеш. | |

3.2. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү

3.2.1. Юридик затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны кисәтү, мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү максатларында Бүлек, ел саен раслана торган хокук бозуларны профилактикалау программасы нигезендә, мәҗбүри таләпләрне,

муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыра.

3.2.2. Мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны профилактикалау максатларында Бүлек:

1) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында үтәлешен бәяләү региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып торган мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актларның яки аларның аерым өлешләренең исемлеген, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстларын урнаштыруны тәэмин итә;

2) мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү буенча кулланмалар эшләү һәм бастырып чыгару, семинарлар һәм конференцияләр үткәрү, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре үткәрү юлы белән һәм башка ысуллар белән юридик затларга мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра. Мәҗбүри таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үзгәргән очракта, Бүлек мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларның гамәлгә керү сроклары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне гамәлгә кертүгә һәм тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру, техник чаралар үткәрү турында тәкъдимнәр әзерли һәм тарата;

3) күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру практикасын даими (кимендә елга бер тапкыр) гомумиләштерүне һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтта (шул исәптән шәһәрнең рәсми сайтында: hhtp://nabchelny.ru/) тиешле гомумиләштерүләрне урнаштыруны, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның аеруча еш очрый торган очракларын күрсәтеп, мондый бозуларны булдырмау максатларында юридик затлар тарафыннан күрелергә тиешле чараларга карата рекомендацияләр белән тәэмин итә;

4) әгәр дә башка тәртип федераль закон белән билгеләнмәгән булса, 294-ФЗ санлы Федераль законның 8.2 маддәсенең 5-7 бүлекләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтә.

3.2.3. Мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүдә тиешле мәҗбүри таләпләргә, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә, аларны күздә тоткан норматив хокукый акт, шулай ук юридик затның конкрет нинди эшләре (эш итмәүләре) бу таләпләрне бозуга китерә алуы яисә китерүе турында мәгълүмат булырга тиеш. Мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү, юридик зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турындагы мәгълүматлардан тыш, юридик зат тарафыннан мәгълүмат һәм документлар бирү таләпләрен үз эченә ала алмый.

3.2.4. Бүлек тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, юридик зат тарафыннан мондый кисәтүгә каршы җавап бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтү үтәлеше турында хәбәр итү Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## 4 бүлек. Тикшерү үткәргәндә юридик зат тарафыннан тапшырыла торган документлар

4.1. Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге.

| Тикшерү үткәрү өчен тапшырыла торган документ | Норматив-хокукый акт |
| --- | --- |
| 4.1.1 Күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен Бүлек тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затлардан алына торган мәгълүматларның һәм (яки) документларның исемлеге<br><br>1) Юридик затның оештыру документлары (устав яки оештыру килешүе һәм устав);<br><br>2) Күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын (алга таба – Объект) төзү (булдыру) өчен гражданнарның һәм юридик затларның акчаларын җәлеп итүче юридик зат җитәкчесен сайлау турында карар һәм вазыйфага билгеләү турында приказ, аның нигезендә ул күрсәтелгән юридик зат исеменнән ышаныч язуыннан башка эш итәргә хокуклы;<br><br>3) Үз-үзен җайга салучы оешмада әгъза булуны яисә үз-үзен җайга салучы оешмада әгъза булу кирәклеге булмауны раслаучы документлар;<br><br>4) Аңа кертелгән барлык үзгәрешләрне үз эченә алган проект документлары;<br><br>5) Объектны төзү проектын техник-икътисадый нигезләү;<br><br>6) Әгәр мондый экспертиза үткәрү федераль законнарда билгеләнгән булса, проект документларына экспертиза һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәсе яисә проект документларын модификацияләнгән проект документлары дип тану турында бәяләмә, шулай ук дәүләт экология экспертизасы нәтиҗәләре (мондый экспертиза үткәрү кирәк булганда);<br><br>7) Объектны төзүче, техник заказчы, подрядчылар һәм проектлаучылар турында мәгълүмат;<br><br>8) Башкарылган эшләрне һәм төзелеш стадияләрен тасвирлап, төзелеше тәмамланмаган объектның әзерлек | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 11 октябрендәге 750 нче карары |

| | |
|---|---|
| дәрәҗәсе турында белешмә, түбәндәгеләр буенча башкарылган эшләр дәрәҗәсен күрсәтеп (процентларда):<br>монолит;<br>кирпеч салу;<br>гомуми файдаланудагы урыннарны бизәкләү;<br>эчке челтәрләр, тышкы челтәрләр, вентиляция, тәрәзәләр, лифтлар монтажлау;<br>электромонтаж эшләре;<br>объектны төзекләндерү;<br><br>9) Төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашу килешүләре һәм (яки) Объект төзү (булдыру) өчен физик һәм (яисә) юридик затларның акчалары җәлеп итүгә нигез булып торган (җәлеп ителә торган) һәм гражданнарның һәм юридик затларның Объекттагы бүлмәгә милекчелек хокукы барлыкка килүгә нигез булып торган башка килешүләр, шулай ук таләпләр хокукын бирү турында килешүләр (цессия килешүләре) (тапшыру акты яки өлешләп төзү объектын тапшыру турында башка документ) буенча йөкләмәләр үтәлешен раслый торган документлар;<br><br>10) Үзгәрешләрне, бастырып чыгару һәм (яки) урнаштыру даталарын һәм чыганакларын күрсәтеп, төзүче һәм төзелеш проекты турындагы мәгълүматны үз эченә алган проект декларациясе;<br><br>11) Залог, төзүче тарафыннан өлешләп төзүнең беренче катнашучысы белән килешү төзелгәннән соң рәсмиләштерелгән очракта, өлешләп төзүдә катнашучыларның 214-ФЗ санлы Федераль законның 13 маддәсенең 1-3 бүлекләрендә күрсәтелгән мөлкәтне залогка тапшыруга ризалыгы;<br><br>12) 214-ФЗ санлы Федераль законның 13 маддәсенең 1-3 бүлекләрендә күрсәтелгән мөлкәтне залогка алучы булып торган банкның 214-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсенең 2 бүлеге нигезендә залогка бирелгән мөлкәт хисабына үз таләпләрен канәгатьләндерүгә һәм 214-ФЗ санлы Федераль законның 13 маддәсенең 8 бүлегендә каралган очракта өлешләп төзү объектларына залог хокукын туктатуга ризалык бирүе;<br><br>13) Өлешләп төзүдә катнашу килешүләре һәм (яки) Объект төзү (булдыру) өчен физик һәм (яисә) юридик затларның акчалары җәлеп итүгә нигез булып торган (җәлеп ителә торган) һәм алар нигезендә гражданнарның һәм юридик затларның Объекттагы бүлмәгә милекчелек хокукы барлыкка килүгә нигез булып торган башка килешүләр, шулай ук таләпләр хокукын бирү турында килешүләр (цессия килешүләре), үзгәрешләр, өстәмәләр, өзү турында килешенүләр; | |

| | |
|---|---|
| 14) Өлешләп төзүнең яңа катнашучысына бурычны күчерү һәм өлешләп төзүдә катнашучы тарафыннан килешү буенча таләпләрнең хокукын бирү килешүләре (алар буенча гражданнар һәм юридик затлар төзелеше тәмамланмаган объекттагы фатирларга мөлкәт хокукларын сатып алган);<br><br>15) Гади ширкәт килешүләре (уртак эшчәнлек турында килешүләр), кысаларында Объект төзү гамәлгә ашырыла торган инвестиция килешүләре;<br><br>16) Объектны төзү (булдыру) өчен төзелгән һәм (яки) төзүченең агымдагы эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле кредит килешүләре һәм займ килешүләре, шулай ук аларның үзгәрешләре, өстәмәләре, аларны өзү турында килешүләр;<br><br>17) Төзелеш подряды, төзелеш материаллары белән тәэмин итү килешүләре, Объектны төзүгә (булдыруга) бәйле башка килешүләр;<br><br>18) Өлешләп төзүдә катнашучыларны (физик затларның фамилиясен, исемен, атасының исемен, юридик затларның исемен), шулай ук Объектны төзү (булдыру) тәмамланганнан соң өлешләп төзүдә катнашучыларга тапшырылачак фатирларның (торак булмаган бүлмәләрнең, парковка урыннарының) санын һәм номерларын күрсәтеп (өлешләп төзүдә катнашу килешүен имзалау датасын һәм номерын; өлешләп төзүдә катнашу килешүен теркәү датасын һәм номерын; өлешләп төзүдә катнашу килешүе төзүгә мөнәсәбәтле бүлмә параметрларын; өлешләп төзүдә катнашу килешүенең бәясен; өлешләп төзүдә катнашу килешүен түләүгә кергән акчалар суммасын күрсәтеп) төзелә (булдырыла) торган Объектларның реестры.<br><br>Реестр йомгаклау юлын үз эченә алырга тиеш, реестр исемендә акча җәлеп итүче төзүченең исеме, Объектнын исеме (төзелешкә рөхсәт нигезендә) һәм реестр төзелгән дата күрсәтелергә тиеш;<br><br>19) Өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең һәм (яки) Объект төзү (булдыру) өчен физик һәм (яисә) юридик затларның акчаларын җәлеп итүгә (җәлеп ителә торган) нигез булып торган һәм гражданнарның һәм юридик затларның Объекттагы бүлмәгә милекчелек хокукы барлыкка килүгә нигез булып торган башка килешүләрнең реестры, түбәндәгеләрне күрсәтеп:<br><br>юридик затның исемен, урнашу урыны адресын, салым түләүченең идентификация номерын;<br><br>физик затның фамилиясен, исемен, атасының исемен | |

| | |
|---|---|
| һәм теркәлү адресын;<br><br>өлешләп төзүдә катнашу килешүен һәм (яки) башка килешүне имзалау, дәүләт теркәвенә алу, өзү датасын;<br><br>өлешләп төзүдә катнашу килешүенең һәм (яки) башка килешүнең һәрберсенең суммасын;<br><br>өлешләп төзүдә катнашу килешүе һәм (яки) башка килешү буенча акча керү датасын.<br><br>Өлешләп төзүдә катнашу килешүенең һәм (яки) башка килешүнең берничә төре булган очракта, реестр килешүнең һәр төренә аерым төзелергә тиеш.<br><br>20) Өзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләренең һәм (яки) алар нигезендә Объект төзү (булдыру) өчен акчалар җәлеп ителгән башка килешүләрнең, өзү сәбәпләре күрсәтелгән реестры;<br><br>21) Төзүче тарафыннан килешүдә каралган срокта төзелешне тәмамлау мөмкин булмау турында өлешләп төзүдә катнашучыларга җибәрелгән белдерү кәгазьләре һәм килешү шартларын үзгәртү турында тәкъдим (почта аша җибәрүне раслап);<br><br>22) Өлешләп төзүдә катнашу килешүләрен һәм (яки) алар нигезендә Объект төзү (булдыру) өчен акчалар җәлеп ителгән башка килешүләрне үтәүдән берьяклы баш тарту турында белдерү кәгазе (почта аша җибәрүне раслап);<br><br>23) Исәпкә алу сәясәте турында приказ, шул исәптән төзүченең финанс-хуҗалык эшчәнлеген исәпкә алу буенча синтетик һәм аналитик счетларны һәм субсчетларны үз эченә алган бухгалтерлык исәбе счетларының эш планнары;<br><br>24) Бухгалтерлык хисабының дөреслеген раслаучы аудитор бәяләмәсе (төзүче тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруның хисап чорлары өчен);<br><br>25) Һәр өлешләп төзү объекты буенча хисап чоры өчен бухгалтерлык балансы статьяларының расшифровкасы;<br><br>26) Бухгалтерлык исәбе документлары турында мәгълүмат, хисап чорлары өчен РФ Хөкүмәтенең 645 нче карары белән расланган Төзүчеләр тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында кварталлык хисап бирү кагыйдәләренә 3 нче кушымта һәм 2 нче кушымтаның 11 графасы нигезендә төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучыларның җәлеп ителгән акчаларыннан файдалану турында графалар тутыруга нигез булып торган | |

| | |
|---|---|
| бухгалтерлык исәбе һәм бухгалтерлык хисабы мәгълүматлары;<br><br>27) Объектларны өлешләп төзүгә акча җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлә ашырганда финанс-хуҗалык операцияләрен исәпкә алуга бәйле бухгалтерлык исәбе регистрлары: журнал-ордерлар, счет карточкалары, субсчетлар, субконто (төзелеш объектлары буенча), Объектларны өлешләп төзүдә катнашучылар (76, 86, 08, 60 счетлары буенча) буенча әйләнеш-сальдо ведомостьлары (аналитик исәп) һәм 50, 51, 76, 86, 08, 60 счетларның карточкалары, шулай ук өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары хәрәкәтенә бәйле башка счетлар;<br><br>28) Касса кенәгәсе, хисап чорлары өчен керем һәм чыгым касса ордерлары;<br><br>29) Хисап чорлары өчен КМ-6 номерлы формада кассир-операцияләрне башкаручының белешмә-хисаплары;<br><br>30) Акчаларның банк счетлары буенча хәрәкәте турында өземтәләр, хисап чорлары өчен түләү йөкләмәләре;<br><br>31) Капиталь төзелештә эшләрне исәпкә алу буенча беренчел исәпкә алу документлары;<br><br>32) Төзелеш материаллары белән тәэмин итү накладнойлары, төзелеш материалларын гамәлдән чыгару актлары;<br><br>33) КС-6 номерлы формада эшләрнең гомуми журналы;<br><br>34) Өлешләп төзүдә катнашу килешүләре һәм (яки) Объектны төзү (булдыру) өчен акча җәлеп итүгә нигез булган башка килешүләр (килешенүләр) буенча хисап чоры ахырына өлешләп төзүдә катнашучыларның дебитор бурычы күләмен күрсәтеп, квартал саен тапшырыла торган белешмә;<br><br>35) Өлешләп төзү Объектын һәм/яки Объект төзү өчен бүленгән җир участогын залогка тапшырып җәлеп ителгән кредит (заем) акчалары күләме күрсәтелгән белешмә;<br><br>36) Инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташу өчен техник шартлар һәм инженерлык-техник тәэмин итү килешүләре;<br><br>37) Үтәү өчен төзүче тарафыннан төзелеш проектын тормышка ашыру гамәлгә ашырыла торган килешүләр (төзелгән территорияне үстерү турында килешү; территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү; | |

| | |
|---|---|
| эконом классы торак төзү максатларында территорияне үзләштерү турында килешү; эконом классы торак төзү максатларында территорияне комплексы үзләштерү турында килешү; хокукка ия затларның инициативасы буенча территорияне комплексы үстерү турында килешү; җирле үзидарә органнары инициативасы буенча территорияне комплексы үстерү турында килешү) (мондый шартнамә төзелгән очракта), шул исәптән шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнарында каралган килешүләр;<br><br>38) Аны тормышка ашыру этаплары һәм сроклары турында, шул исәптән Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт алуның күз алдында тотылган срогы турында мәгълүматны үз эченә алган төзелеш проектын тормышка ашыру графигы;<br><br>39) Җитәкче тарафыннан имзаланган әлеге исемлек нигезендә тапшырылган һәр документның исеме күрсәтелгән исемлек.<br><br>Исемлектә күрсәтелгән документлар, оешма җитәкчесе тарафыннан расланган һәм оешма мөһере белән таныкланган (федераль законда мөһрдән файдалану бурычы йөкләнгән очракта) күчермәләр (документ берничә биттән торган очракта, шнурланган, номерлар сугылган) рәвешендә Объект төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүне гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан тапшырыла.<br><br>4.1.2. Торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм торак-төзелеш кооперативыннан һәм шундый кооператив белән күп фатирлы йорт төзүгә бәйле килешүләр төзегән затлардан алына торган документлар һәм мәгълүматлар исемлеге<br><br>1) Торак-төзелеш кооперативының оештыру документлары;<br><br>2) Аңа кертелгән барлык үзгәрешләрне үз эченә алган проект документлары;<br><br>3) Үз-үзен җайга салучы оешмада әгъза булуны яисә үз-үзен җайга салучы оешмада әгъза булу кирәклеге булмауны раслаучы документлар;<br><br>4) проект документларына үзгәрешләр кертү мәсьәләләре буенча торак-төзелеш кооперативы әгъзалары | |

гомуми җыелышының карары;

5) Объектны төзү проектын техник-икътисадый нигезләү;

6) әгәр мондый экспертиза үткәрү федераль законнарда билгеләнгән булса, проект документларына экспертиза һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәсе яисә проект документларын модификацияләнгән проект документлары дип тану турында бәяләмә, шулай ук дәүләт экология экспертизасы нәтиҗәләре (мондый экспертиза үткәрү кирәк булганда);

7) объектны төзүче, техник заказчы, подрядчылар һәм проектлаучылар турында мәгълүмат;

8) башкарылган эшләрне һәм төзелеш стадияләрен тасвирлап, төзелеше тәмамланмаган объектның әзерлек дәрәҗәсе турында белешмә, түбәндәгеләр буенча башкарылган эшләр дәрәҗәсен күрсәтеп (процентларда):
монолит;
кирпеч салу;
гомуми файдаланудагы урыннарны бизәкләү;
эчке челтәрләр, тышкы челтәрләр, вентиляция, тәрәзәләр, лифтлар монтажлау;
электромонтаж эшләре;
объектны төзекләндерү;

9) Торак-төзелеш кооперативының ревизия комиссиясе (ревизор) бәяләмәләре;

10) Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Объект төзү (булдыру) өчен физик һәм (яисә) юридик затларның акчалары җәлеп итүгә нигез булып торган (җәлеп ителә торган) һәм гражданнарның һәм юридик затларның Объекттагы бүлмәгә милекчелек хокукы барлыкка килүгә нигез булып торган килешүләр буенча йөкләмәләр үтәлешен раслый торган документлар;

11) Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан төзелгән Объект төзү (булдыру) өчен физик һәм (яисә) юридик затларның акчалары җәлеп итүгә нигез булып торган (җәлеп ителә торган) һәм алар нигезендә гражданнарның һәм юридик затларның Объекттагы бүлмәгә милекчелек хокукы барлыкка килүгә нигез булып торган килешүләр;

12) Торак-төзелеш кооперативы әгъзаларын (физик затларның фамилиясен, исемен, атасының исемен, юридик затларның исемен), шулай ук Объектны төзү (булдыру) тәмамланганнан соң торак-төзелеш кооперативы әгъзаларына тапшырылачак фатирларның, торак булмаган бүлмәләрнең, парковка урыннарының санын һәм номерларын күрсәтеп (килешүне имзалау датасын һәм

| | |
|---|---|
| номерын; килешү төзегән физик затның фамилиясен, исемен, атасының исемен яки юридик затның исемен; килешү төзүгә мөнәсәбәтле булмә параметрларын; килешүне түләүгә кергән акчалар суммасын (кереш һәм пай взнослары күләмен) күрсәтеп төзелә (булдырыла) торган Объектларның реестры.<br><br>Реестр йомгаклау юлын үз эченә алырга тиеш, реестр исмендә акча җәлеп итүче торак-төзелеш кооперативының исеме, Объектның исеме (төзелешкә рөхсәт нигезендә) һәм реестр төзелгән дата күрсәтелергә тиеш;<br><br>13) Объектны төзү (булдыру) өчен төзелгән һәм (яки) төзүченең агымдагы эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле кредит килешүләре һәм займ килешүләре, шулай ук аларның үзгәрешләре, өстәмәләре, аларны өзү турында килешүләр;<br><br>14) Төзелеш подряды, төзелеш материаллары белән тәэмин итү килешүләре, Объектны төзүгә (булдыруга) бәйле башка килешүләр;<br><br>15) Исәпкә алу сәясәте турында приказ, шул исәптән төзүченең финанс-хуҗалык эшчәнлеген исәпкә алу буенча синтетик һәм аналитик счетларны һәм субсчетларны үз эченә алган бухгалтерлык исәбе счетларының эш планнары;<br><br>16) Түбәндәгеләрне үз эченә алган, төзелешне финанслау буенча белешмә:<br><br>финанслау чыганагын күрсәтеп, Объект төзүгә акчалар җәлеп итүче торак-төзелеш кооперативы тарафыннан алынган акчалар суммасы турында;<br><br>чыгым статьяларын күрсәтеп, үзләштерелгән капиталь салулар бәясе турында;<br><br>заказчы хезмәтләренең бәясе турында (алар булган очракта);<br><br>башкарылган эшләр, хезмәтләргә түләү буенча дебитор һәм кредитор бурычы булу;<br><br>дебитор һәм кредитор бурычларын исәпкә алып, Объект төзүгә акчалар җәлеп итүче торак-төзелеш кооперативы тарафыннан сарыф ителгән акчалар суммасы турында;<br><br>Объект төзү өчен калган акчалар турында.<br><br>Белешмәдә күрсәтелгән барлык мәгълүматлар бухгалтерлык документлары: журнал-ордерлар, әйләнеш-сальдо ведомостьлары, субконто карточкалары, касса кенәгәсе, төп кенәгә, банк өземтәләре һәм (яки) башка | |

| | |
|---|---|
| бухгалтерлык документлары, шулай ук белешмә бирү датасына торак-төзелеш кооперативы счетларында калган акчаларны раслаучы банк белешмәләре белән расланган булырга тиеш.<br><br>17) Бухгалтерлык хисабының дөреслеген раслаучы аудитор бәяләмәсе (төзүче тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруның хисап чорлары өчен);<br><br>18) Түбәндәгеләргә чыгымнарны раслаучы документлар:<br>Объект төзү буенча эшләр башкаруга;<br>башкарылган эшләр өчен түләүгә;<br>Объект төзү өчен чыгымнарны бүлүгә;<br>Объектны төзү гамәлгә ашырыла торган акчалар керүгә;<br>Объектны төзү өчен кергән акчаларны сарыф итүгә.<br><br>Акчалар керү һәм аларны сарыф итү бухгалтерлык исәбенең беренчел документлары (түләү йөкләмәләре, банк өземтәләре, керем-касса ордерлары, касса кенәгәләре) белән раслана.<br><br>19) Торак-төзелеш кооперативы әгъзалары гомуми җыелышларының беркетмәләре, торак-төзелеш кооперативы идарә утырышларының беркетмәләре һәм торак-төзелеш кооперативы ревизия комиссияләренең (ревизорының) беркетмәләре;<br><br>20) Тавыш бирү йомгакларын раслаучы документлар, шул исәптән тавыш бирү өчен бюллетеньнәр һәм торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышында катнашу өчен ышыныч язулары яки шундый ышаныч язуларының күчермәләре.<br><br>Әлеге исемлектә күрсәтелгән документлар, оешма җитәкчесе тарафыннан расланган һәм оешма мөһере белән таныкланган (федераль законда мөһрдән файдалану бурычы йөкләнгән очракта) күчермәләр (документ берничә биттән торган очракта, шнурланган, номерлар сугылган) рәвешендә торак-төзелеш кооперативы һәм кооператив Объект төзүгә (булдыруга) бәйле килешү төзегән башка затлар тарафыннан тапшырыла. | |

4.2. Тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә Бүлек бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге документларны соратып ала:

4.2.1. Күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашырганда:

1) Юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык яки физик затны шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәвенә алу турында таныклык;

2) Россия Федерациясе территориясендә урнашу урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык;

3) Объект төзүгә рөхсәт;

4) Төзелеше тәмамланмаган объектка милекчелек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм теркәү гамәлләрен башкару өчен нигез булып торган документлар;

5) Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының вазыйфаи затлары тарафыннан төзелә торган төзелеше тәмамланган Объектны тикшерү акты, төзелгән Объектның техник регламентларның һәм проект документларынын таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм объектның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының бәяләмәсе, Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт;

6) Объектны төзү (булдыру) өчен бирелгән җир участогына бирелгән милекчелек хокукын, аренда хокукын, субаренда хокукын яисә түләүсез сроклы файдалану хокукын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (дәүләт теркәү номеры, теркәү датасы) һәм теркәү гамәлләрен башкару өчен нигез булып торган документлар;

7) Җир участогының кадастр планы;

8) Төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза бирелгән көнгә кадәр өч елдан артмаган срокта бирелгән җир участогының шәһәр төзелеше планы;

9) Төзелеш өчен рөхсәт алынган вакыттан башлап хисап чорлары өчен (алга таба – квартал өчен, бер ел өчен) юридик затның бухгалтерлык хисабы (бухгалтерлык балансы, керемнәр һәм чыгымнар турында хисап, капитал үзгәреше турында хисап, акчалар хәрәкәте турында хисап, бухгалтерлык балансына башка кушымталар).

4.2.2. Торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда:

1) Төзелештә торак-төзелеш кооперативы әгъзалары үз акчалары белән катнаша торган күп фатирлы йортны (алга таба – Объект) төзүгә рөхсәт;

2) Объектны төзү (булдыру) өчен бирелгән җир участогына бирелгән милекчелек хокукын, аренда хокукын, субаренда хокукын яисә түләүсез сроклы файдалану хокукын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (дәүләт теркәү номеры, теркәү датасы) һәм теркәү гамәлләрен башкару өчен нигез булып торган документлар;

3) Төзелеше тәмамланмаган объектка милекчелек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм теркәү гамәлләрен башкару өчен нигез булып торган документлар;

4) Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының вазыйфаи затлары тарафыннан төзелә торган төзелеше тәмамланган Объектны тикшерү акты, төзелгән Объектның техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм объектның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының бәяләмәсе, Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт;

5) Җир участогының кадастр планы;

6) Төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза бирелгән көнгә кадәр өч елдан артмаган срокта бирелгән җир участогының шәһәр төзелеше планы;

7) Төзелеш өчен рөхсәт алынган вакыттан башлап хисап чорлары өчен (алга таба – квартал өчен, бер ел өчен) юридик затның бухгалтерлык хисабы (бухгалтерлык балансы, керемнәр һәм чыгымнар турында хисап, капитал үзгәреше турында хисап, акчалар хәрәкәте турында хисап, бухгалтерлык балансына башка кушымталар).

## 5 бүлек. Административ процедуралар

5.1. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре

5.1.1. Административ процедураларның исемлеге:

1) планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планын әзерләү;

2) өлешләп төзү турында закон таләпләре үтәлешенә планлы тикшерүләр һәм планнан тыш тикшерүләр оештыру һәм үткәрү;

3) мәҗбүри таләпләрне бозуны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм үткәрү;

4) төзүченең кварталлык хисабын кабул итү һәм анализлау;

5) торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында төзүче тарафыннан мәгълүмат ачуга таләпләр үтәлешен тикшерү;

6) торак-төзелеш кооперативының күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен гамәлгә ашыру.

5.1.2. Административ процедураларны үтәү өчен җавалы вазыйфаи затлар булып Бүлек белгечләре тора.

5.1.3. Дәүләт функциясен үтәү буенча блок-схема административ регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән.

5.2. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планын әзерләү

5.2.1. Планлы тикшерүләр эшләнгән планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба – тикшерүләр планы) нигезендә үткәрелә.

Планлы тикшерүләрне еллык тикшерүләр планына кертү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затка төзелешкә рөхсәт бирелгән датадан башлап бер ел узу;

2) Яр Чаллы шәһәре территориясендә шундый затны соңгы тапкыр планлы тикшерүне үткәрү тәмамланган датадан башлап бер ел узу.

Юридик затларны (аларның филиалларын, вәкиллекләрен, аерымланган структур бүлекчәләрен) һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүләрне үткәрүнең еллык планында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) планлы рәвештә тикшерелергә тиешле юридик затларның (аларның филиалларын, вәкиллекләрен, аерымланган структур бүлекчәләрен) исеме, шәхси эшмәкәрләрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу урыны яки шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлекләрен фактик гамәлгә ашыру урыны;

2) һәр планлы тикшерү үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) Һәр планлы тикшерү ткәрүне башлау датасы һәм сроклары;

4) конкрет планлы тикшерүне гамәлгә ашыра торган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының яки муниципаль контроль органының исеме. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан планлы тикшерү үткәргәндә мондый тикшерүдә катнашучы барлык органнарның исемнәре бергә күрсәтелә.

Планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы агымдагы елның 1 сентябренә кадәр срокта планлы тикшерүләр үткәрү планының проекты шәһәр Прокуратурасына (алга таба – прокуратура) җибәрелә. Прокуратура кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен алганнан соң һәм аларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы елның 1 ноябренә кадәр планлы тикшерүләр үткәрүнең

расланган еллык планы прокуратурага җибәрелә. План Бүлек башлыгы тарафыннан килешенә һәм шәһәр Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан раслана.

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планын әзерләү, аны прокуратурага җибәрү һәм килешенү тәртибе, шулай ук планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планының типовой формасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Башкарма комитет боерыгы белән расланган планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында (http://nabchelny.ru) урнаштырып яисә башка уңайлы ысул ярдәмендә кызыксынган затларга җиткерелә.

5.3. Өлешләп төзү турында закон нигезләмәләре үтәлешен планлы тикшерүне һәм планнан тыш тикшерүне оештыру һәм үткәрү

5.3.1. Планлы тикшерүне оештыру һәм үткәрү

5.3.2. Планлы тикшерүне үткәрү предметы булып төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затлар тарафыннан 214-ФЗ санлы Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлеше тора.

5.3.3. Планлы тикшерүне үткәрү өчен нигез булып тикшерүләр үткәрүнең еллык планы һәм Башкарма комитет Җитәкчесенең күрсәтелгән план нигезендә кабул ителгән планлы тикшерү үткәрү турындагы боерыгы тора.

5.3.4. Планлы тикшерү 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 һәм 12 маддәләрендә билгеләнгән тәртиптә, документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү рәвешендә үткәрелә.

5.3.5. Башкарма комитетның тикшерү үткәрү турындагы боерыгы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 30 сентябрендәге 620 нче боерыгы нигезендә эшләнә.

5.3.6. Төзүчеләргә планлы тикшерү үткәрү турында, ул үткәрелә башлаганчы өч эш көненнән дә соңга калмый, Башкарма комитетның планлы тикшерү үткәрелә башлау турындагы боерыгы күчермәсен түбәндәге ысулларның берсеннән файдаланып җибәрү юлы белән Бүлек тарафыннан хәбәр ителә:

- почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат җибәреп;
- көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ ярдәмендә;
- әгәр шундый адрес элек Бүлеккә бирелгән (шул исәптән тикшерелә торган затның проект декларациясендә күрсәтелгән) булса, төзүченең электрон почта адресы буенча;
- имза куйдырып, кулга тапшыру;
- мәгълүмат алуны билгеләргә мөмкинлек бирүче башка уңайлы ысул белән.

5.3.7. Планнан тыш тикшерүне оештыру һәм үткәрү

5.3.8. Планлы тикшерүнең предметы булып төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан 214-ФЗ санлы Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең, Бүлек күрсәтмәләренең үтәлеше тора.

5.3.9. Планнан тыш тикшерүне оештыру тәртибе Административ регламентның 3.3.5 пунктчасында билгеләнгән.

5.3.10. Планнан тыш тикшерүнең нигезе булып түбәндәгеләр тора:

1) күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан әлеге 214-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен бозуларны бетерү турында контрольдә тотучы орган тарафыннан бирелгән күрсәтмәне, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, вәкаләтле органның норматив хокукый актлары белән билгеләнгән күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итү мәсьәләләре буенча башка таләпләрне үтәү срогы чыгу (әгәр күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан шундый срок чыкканчы күрсәтмәдә күрсәтелгән кимчелекләр бетерелмәгән булса);

2) төзүченең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында кварталлык хисабын, Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән бухгалтерлык хисабын (шул исәптән еллык) һәм (яки) проект декларациясен анализлауны үткәрү барышында күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турындагы законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыклану;

3) контрольдә тотучы органга 214-ФЗ санлы Федераль законның, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларының, вәкаләтле органның норматив хокукый актларының, җирле үзидарә органнары актларының таләпләрен бозу фактлары турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан 214-ФЗ санлы Федераль законның 23.2 маддәсенең 1 бүлегендә күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмадан, масскүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән мәгълүмат керү;

4) төзүченең төзелеш проектын тормышка ашыру графигыннан алты һәм аннан күбрәк айга тайпылуы.

5) әлеге Федераль законның һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының мәҗбүри таләпләрен бозулар ачыкланган бозган очракта, Россия Федерациясе Президентының яки Россия Федерациясе Хөкүмәтенең яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органының йөкләмәсе нигезендә кабул ителгән контрольдә тотучы орган җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) планнан тыш тикшерү үткәрү турында приказы (боерыгы);

6) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе;

7) контрольдә тотучы органга вәкаләтле банктан 214-ФЗ санлы Федераль законның 18.2 маддәсенең 4 бүлегендә каралган белдерү кәгазе керү.

Административ регламентның 3.3.10 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча, планнан тыш күчмә тикшерү 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсенең 12 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, кичектергесез рәвештә прокуратура органына хәбәр итеп, контрольдә тотучы орган тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

Дәүләт функциясен үтәүгә мөнәсәбәтле затка күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында алдан хәбәр итү рөхсәт ителми.

5.3.11. Үткәрү нигезләре 294-ФЗ санлы Федераль законның 2 бүлегенең 2 пунктында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән тыш, планнан тыш күчмә тикшерү турында ул үткәрелә башлаганчы 24 сәгатьтән дә ким булмаган вакытта, төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затларга теләсә кайсы уңайлы ысул белән, шул исәптән, әгәр шундый адрес бердәм дәүләт юридик затлар реестрында булса яисә элек юридик зат тарафыннан Бүлеккә бирелгән булса, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм электрон почта адресы буенча җибәрелгән электрон документ ярдәмендә хәбәр ителә.

5.3.12. 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 һәм 12 маддәләрендә каралган тикшерүләрнең һәрберсен үткәрү вакыты егерме эш көненнән артырга тиеш түгел.

5.3.13. Мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат Административ регламентның 3.3.10 пунктындагы 3 пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып торган очракта, мөрәҗәгать яки гариза авторы турында нигезле шикләр булса, Бүлекнең вазыйфаи заты мөрәҗәгать иткән затны билгеләүгә карата тиешле чаралар күрергә тиеш. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, гариза бирүче тарафыннан гариза бирүчене бердәм идентификация һәм аутентификация системасында мәҗбүри авторизацияләүне күздә тоткан мәгълүмат-коммуникация технологияләре чараларын кулланып җибәрелгән очракта гына планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып тора ала.

5.3.14. Административ регламентның 3.3.10 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны карап тикшергәндә, элек кергән шундый мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре, шулай ук тиешле тикшерелүче затларга карата элек үткәрелгән контроль чараларның нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

5.3.15. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, мәҗбүри таләпләрне бозу турында яисә Административ регламентның 3.3.10 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар булмаганда, Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан кергән мәгълүматны алдан тикшерү үткәрелергә мөмкин. Алдан тикшерү барышында гаризалар һәм мөрәҗәгатльләр җибәргән, мәгълүмат биргән затлардан өстәмә мәгълүматлар һәм материаллар (шул исәптән телдән) соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең Бүлек карамагында булган документларын карап тикшерү үткәрелә, кирәк булганда, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә мәгълүмат тапшыру һәм Бүлек таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә, күрсәтелгән затлар белән үзара бәйләнешсез гамәлгә ашырыла торган контроль чаралары үткәрелә. Алдан тикшерү кысаларында юридик заттан алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратып алынырга мөмкин, әмма мондый аңлатмаларны һәм башка документларны тапшыру мәҗбүри түгел.

5.3.16. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган затларны алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу турында яисә Административ регламентның 3.3.10 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар алыну ачыкланган очракта, Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи заты Административ регламентның 3.4.3 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерүне билгеләү турында дәлилләнгән күрсәтмә әзерли. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерелүче затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

5.3.17. Тиешле тикшерү башланганнан соң аны оештыру өчен сәбәп булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланган яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада күрәләтә дөрес булмаган мәгълүматлар күрсәтелү билгеләнгән очракта

Бүлек башлыгы карары буенча алдан тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

5.3.18. Гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә күрәләтә ялган мәгълүматлар күрсәтелгән очракта, Бүлек күрсәтелгән затлардан кергән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү сәбәпле, Бүлек тарафыннан тотылган чыгымнарны гражданнан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән түләтү турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.3.19. Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып тикшерү Акты (алга таба – тикшерү Акты) (РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче приказына 3 нче кушымта) тора.

Тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре һәм ачыкланган кимчелекләрне бетерү өчен күрелергә (күрелгән) тиешле чаралар чагылдырыла:

1) күрсәтмә җибәрергә (җибәрелгән);

2) материалларны хокук саклау органнарына тапшырырга.

Тикшерү акты турыдан-туры планнан тыш тикшерү тәмамланганнан соң ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе, кушымталарның күчермәләре белән бергә җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышу турында яки танышудан баш тарту турында расписка буенча бирелә. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче зат тикшерү Акты белән танышу турында яки танышудан баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, Акт тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән җибәрелә, тапшыру турында белдерү кәгазе делода саклананучы тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү өчен, аны үткәрүне прокуратура белән килешенү таләп ителгән очракта, тикшерү Актының күчермәсе кушымталары белән бергә тикшерү Акты төзелгән көннән башлап 5 эш көне эчендә прокуратурага җибәрелә.

5.3.20. Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе Яр Чаллы шәһәре территориясендә төзелешне гамәлгә ашыручы юридик затны тикшерүләрне исәпкә алу журналында теркәлә. Тикшерү Акты нөсхәсе Бүлектә саклана, аның күчермәләрен бирү хокук саклау һәм суд органнарының запрослары буенча күздә тотыла.

5.3.21. Административ процедураны үтәү нәтиҗәләре тикшерү тәмамланган көннән башлап өч эш көне эчендә Федераль мәгълүмат системасы сайтында Бердәм тикшерүләр реестры урнаштырыла, ә тикшерү үткәрү өчен нигез булып гражданнарның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары торса – 5 эш көне эчендә.

5.4. Төзүченең күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзүче тарафыннан төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графигын, килешүләр буенча үз йөкләмәләрен үтәү турында кварталлык хисабын, шулай ук арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын кабул итү һәм анализлау.

5.4.1. Административ процедураны башлау өчен нигез булып, төзүче тарафыннан күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзүче тарафыннан төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графигын, килешүләр буенча үз йөкләмәләрен үтәү турында кварталлык хисабын, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетына тапшыру тора.

5.4.2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) кулга тапшыру юлы белән яки почта элемтәсе аша кергән хисап эш көне дәвамында, Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең бурычларына керүче корреспонденцияне теркәү кергән вазыйфаи заты тарафыннан теркәлә.

5.4.3. Төзүченең кварталлык хисабын анализлаганда, Бүлекнең анализ үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи заты Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләренең төзүче тарафыннан түбәндәгеләр өлешендә үтәлеше билгеләнә:

1) хисап бирүнең 214-ФЗ санлы Федераль законда, РФ Хөкүмәтенең 2005 елның 27 октябрендәге 645 нче карары белән расланган Төзүчеләрнең өлешләп төзүдә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында кварталлык хисабын бирү кагыйдәләрендә билгеләнгән срогының үтәлеше;

2) Кагыйдәләр нигезендә хисап төзелешенең үтәлеше;

3) хисапны рәсмиләштерүгә һәм тутыруга карата Кагыйдәләрдә, Финанс базарлары буенча Федераль хезмәтнең 2006 елның 12 гыйнварындагы 06-2/пз-н санлы боерыгы белән расланган Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрнең кварталлык хисап формаларын тутыру буенча методик күрсәтмәләрдә каралган таләпләрнең үтәлеше;

4) РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 21 апрелендәге 233 нче карары белән билгеләнгән төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативлаврының үтәлеше;

5) хисапта бирелгән мәгълүматларның дөреслеге.

5.4.4. Хисапны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Бүлек тарафыннан 2 нөсхәдә төзүченең кварталлык хисабын тикшерү Акты төзелә.

5.4.5. Тапшырылган хисапта өлешләп төзү өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозулар ачыкланган очракта, Бүлек белгече тарафыннан күп фатирлы йортларны һәм (башка) күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозуларны бетерү турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә) чыгарыла.

5.4.6. Күрсәтмә ике нөсхәдә төзелә, аларның берсе төзүченең кварталлык хисапбын тикшерү акты белән бергә расписка буенча җитәкчегә (башка вазыйфаи затка яки төзүченең вәкаләтле вәкиленә) тапшырыла яисә тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән җибәрелә, шулай ук торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.

5.4.7. Административ гамәлләр срогы Бүлек белгече тарафыннан күрсәтмә чыгарылган көннән башлап 3 эш көненнән дә артмый. Заказлы хатны тапшыру турында белдерү кәгазе тикшерү материалларына теркәлә.

5.4.8. Кварталлык хисаптагы мәгълүматларның дөреслеге, өлешләп төзүдә катнашу турындагы законнарның үтәлешен тикшерүне үткәрү кысаларында, өстәмә рәвештә тикшерелергә мөмкин.

5.4.9. Хисапларның төп нөсхәләре Бүлектә саклана, аларны бирү хокук саклау һәм суд органнарының запрослары буенча күздә тотыла.

5.4.10. Административ процедураны үтәүнең максималь срогы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетына хисап кергән көннән башлап 60 эш көнен тәшкил итә.

5.5. Төзүче тарафыннан торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында мәгълүмат ачу таләпләренең үтәлешен тикшерү

5.5.1. Административ процедураны үти башлауга нигез булып төзүчегә, төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү тора.

5.5.2. Административ процедураны үткәрү, төзүче тарафыннан 214-ФЗ санлы Федераль законның 3.1 маддәсендә билгеләнгән торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында мәгълүматны ачуга карата таләпләрнең үтәлешен тикшерү рәвешендә үткәрелә.

5.5.3. Тикшерү предметы булып, төзүче тарафыннан түбәндәге мәгълүматларны торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында (https://наш.дом.рф) урнаштыру тәртибе һәм сроклары тора:

1) 214-ФЗ санлы Федераль законның 20 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр;

2) төзелешкә рөхсәт;

3) мондый экспертиза үткәрү федераль законда билгеләнгән булса, проект документларына экспертиза бәяләмәсе;

4) төзүченең җир участогына хокукын раслаучы документлар;

5) проект декларациясе;

6) төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында Башкарма комитет бәяләмәсе;

7) өлешләп төзүдә катнашу килешүенең проекты яки әлеге Федераль закон таләпләренә җавап бирә торган күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү өчен төзүче тарафыннан файдаланыла торган мондый килешүләрнең проектлары;

8) өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын эскроу счетларында урнаштырган очракта, 214-ФЗ санлы Федераль законның 15.4 һәм 15.5 маддәләре таләпләре нигезендә өлешләп төзүдә катнашу килешүе буенча мондый акчаларны җәлеп итү шартлары;

9) төзүченең еллык бухгалтерлык (финанс) хисабына аудитор бәяләмәсе;

10) арадаш хисап чорларына – беренче кварталга, ярты еллыкка һәм тугыз айга кварталлык хисап нигезендә арадаш бухгалтерлык (финанс) хисабы. Төзүче арадаш бухгалтерлык (финанс) хисабын тиешле арадаш хисап чоры тәмамланганнан соң утыз календарь көннән дә соңга калмыйча һәм еллык бухгалтелык (финанс) хисабын һәм аудитор бәяләмәсен тиешле хисап елы тәмамланганнан соң йөз егерме календарь көннән дә соңга калмыйча ача;

11) өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, төзүче тарафыннан төзелә (булдырыла) торган күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзүнең (булдыруның) агымдагы торышын чагылдыручы фоторәсемнәр;

12) җир участогының шәһәр төзелеше планы;

13) капиталь төзелеш объектын, подъездларны һәм аңа керү урыннарын, ачык сервитутларның гамәлдә булу зоналары чикләрен, археологик мирас объектларын урнаштыру урыннарын билгеләп, җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыруны оештыру схемасы;

14) төзүченең үз акчалары күләменең һәм финанс тотрыклылыгы нормативларының исәбе турында мәгълүматны үз эченә алган документ;

15) «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә банкротлык эшендә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында мәгълүматлар;

16) шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә җибәрелгән капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү башлау турында хәбәр;

17) мондый счет номерын, вәкаләтле банк һәм аның идентификаторларын (салым түләүченең идентификация номерын, төп дәүләт теркәү номерын) күрсәтеп, төзүченең исәп-хисап счетын ачу турында яки ябу турында мәгълүматлар;

18) 214-ФЗ санлы Федераль законда каралган башка мәгълүмат.

5.5.4. Төзүче тарафыннан торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган һәр күп фатирлы йортка һәм (яки) башка күчемсез милек объектына мөнәсәбәтле мәгълүматны ачу тәртибенә таләпләр РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 11 маендагы 275/пр санлы боерыгы белән билгеләнгән.

5.5.5. Административ регламентның 3.6.3 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат, төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты бәяләмәсен алынганнан соң 5 эш көне эчендә, 214-ФЗ санлы Федераль законның 23.3 маддәсендә күрсәтелгән торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш. Административ регламентның 3.6.3 пунктының 11 пунктчасында күрсәтелгән фоторәсемнәр ай саен торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.

Административ регламентның 3.6.3 пунктының 13 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлар, бер үк вакытта квартал саен арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын урнаштырып, төзүче тарафыннан күрсәтелгән системада урнаштырылырга тиеш.

5.5.6. 214-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә мәгълүматларга һәм документларга кертелгән һәм ачылырга тиешле үзгәрешләр, әлеге үзгәрешләр кертелгән көннән башлап өч эш көне эчендә торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.

5.5.7. Административ процедураны үтәүнең максималь срогы – 20 эш көне, периодик рәвештә кабатлануы – ай саен.

5.5.8. Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып, төзүче тарафыннан торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында мәгълүматны ачуга куелган таләпләрне тикшерү акты тора.

5.6. Торак-төзелеш кооперативының күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә дәүләт контролен гамәлгә ашыру

5.6.1. Административ процедураны үти башлауга нигез булып торак-төзелеш кооперативын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру тора.

5.6.2. Торак-төзелеш кооперативының күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшерү предметы булып түбәндәгеләр тора:

1) киләчәктә күп фатирлы йортны карап тотудан тыш, Россия Федерациясе Торак кодексының 110 маддәсенең 3 бүлеге таләпләрен үтәү;

2) Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 маддәсе таләпләрен үтәү өлешендә торак-төзелеш кооперативының эшчәнлеге;

3) торак кооперативы вазыйфаи затларының Россия Федерациясе Торак кодексының 116.1 маддәсенең 1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе.

5.6.3. Административ процедура 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 һәм 12 маддәләрендә билгеләнгән тәртиптә, планлы һәм планнан тыш тикшерүләр рәвешендә документар һәм (яки) күчмә формада үткәрелә.

5.6.4. Контрольне гамәлгә ашырганда Бүлек белгечләре түбәндәгеләргә хокуклы:

1) рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру буенча функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органыннан һәм аның территориаль органнарыннан торак-төзелеш кооперативының күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә алырга;

2) торак-төзелеш кооперативы тарафыннан мәгълүмат һәм документлар урнаштыруга карата Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 маддәсенең 1 бүлегендә билгеләнгән таләпләр үтәлешен тикшереп торырга;

3) җирле үзидарә органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны (шул исәптән күп фатирлы йорт төзү белән бәйле документлар) алырга;

4) Россия Федераль салым хезмәтенең Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсеннән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә (анда булган белешмәләр), торак-төзелеш кооперативларының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат алырга;

5) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Баш идарәсеннән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федерациясе Торак кодексының 116.1 маддәсенең 1 пунктында билгеләнгән таләпләр үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны алырга;

6) Яр Чаллы шәһәре буенча Федераль теркәү хезмәте, кадастр һәм картография идарәсеннән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны алырга;

7) торак-төзелеш кооперативыннан һәм мондый кооператив белән күп фатирлы йорт төзүгә бәйле килешүләр төзегән башка затлардан, 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 маддәсендә билгеләнгән срокта, торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм исемлеге Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган документларны һәм мәгълүматны алырга;

8) торак-төзелеш кооперативыннан квартал саен торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча һәм тәртиптә, шундый кооператив тарафыннан кооператив әгъзалары һәм башка затлар алдында үз йөкләмәләрен үтәү турында турында хисап, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын алырга;

9) административ регламентның 3.5.2 пункты нигезендә, торак-төзелеш кооперативының күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшерүне гамәлгә ашырырга;

10) торак-төзелеш кооперативы идарәсе органнарыннан ачыкланган кимчелекләрне бетерүне таләп итәргә;

11) киләчәктә күп фатирлы йортны карап тотудан тыш, РФ Торак кодексының 110 маддәсенең 3 бүлеге таләпләрен һәм РФ Торак кодексының 123.1 маддәсе таләпләрен бозуга бәйле гражданнар һәм юридик затларның шикаятьләрен карап тикшерергә;

12) күп фатирлы йорт төзүдә үз акчалары белән катнашучы торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының әлеге бүлектә каралган хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган очракта, шундый хокукларны һәм мәнфәгатьләрны яклап, судка гариза белән мөрәҗәгать итү өчен материаллар әзерләргә;

13) киләчәктә күп фатирлы йортны карап тотудан тыш, РФ Торак кодексының 110 маддәсенең 3 бүлеге һәм РФ Торак кодексының 123.1 маддәсе таләпләрен бозуларны бетерү турында үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәне торак-төзелеш кооперативына җибәрергә һәм мондый кимчелекләрне бетерү срокларын билгеләргә;

15) җинаять билгеләре буенча җинаять эше кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен, мәҗбүри таләпләрне бозу белән бәйле материалларны хокук саклау органнарына җибәрергә;

16) федераль законнарда каралган башка вәкаләтләрне тормышка ашырырга.

5.6.5. Административ процедураны үтәгәндә түбәндәгеләр тикшерелә:

1) торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасында түбәндәге документларны һәм мәгълүматны урнаштыру:

- торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының саны;

- төзелештә торак-төзелеш кооперативы әгъзалары үз акчалары белән катнаша торган күпфатирлы йорт төзелешенә рөхсәт;

- җир участогына торак-төзелеш кооперативының хокуклары, шул исәптән җир участогына хокук билгеләүче документ реквизитлары, җир участогының хуҗасы турында мәгълүматлар (торак-төзелеш кооперативы җир участогының хуҗасы булып тормаган очракта), күп фатирлы йорт төзү өчен бирелгән җир участогының кадастр номеры һәм мәйданы, төзекләндерү элементлары турында мәгълүматлар;

- төзелә торган күп фатирлы йортның урнашу урыны һәм аның төзелешкә рөхсәт бирү өчен нигез булып торган проект документлары нигезендә әзерләнгән тасвирламасы;

- төзелә торган күп фатирлы йортта торак бүлмәләр саны, проект документлары нигезендә мондый торак бүлмәләрнең техник характеристикаларының тасвирламасы, шулай ук, проект документларына тиешле үзгәрешләр кертелгән очракта, күрсәтелгән мәгълүматны үзгәртү;

- төзелә торган күп фатирлы йортны файдалануга тапшыру өчен рөхсәт алуның күздә тотылган срогы;

2) РФ Торак кодексының 123.1 маддәсенең 3 бүлеге таләпләре нигезендә мәгълүматларны үз эченә алган кооператив әгъзалары реестрын алып бару;

3) РФ Торак кодексының 123.1 маддәсенең 2 һәм 4 бүлекләре таләпләрен үтәү;

4) бер үк вакытта өч каттан артмаган күп фатирлы бер йорт төзелешен гамәлгә ашыру буенча таләпләрне үтәү.

Бүлек белгечләре торак-төзелеш кооперативы әгъзалары реестрындагы мәгълүматларны, шулай ук РФ Торак кодексының 123.1 маддәсендә каралган башка мәгълүматны торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасыннан ала.

5.6.6. Торак-төзелеш кооперативына төзелешкә рөхсәт бирелгән датадан соң яисә Яр Чаллы шәһәре территориясендә мондый кооперативны соңгы тапкыр планлы тикшерүне үткәрү тәмамланган дата соң соң бер ел узу планлы тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора.

5.6.7. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) киләчәктә күп фатирлы йортны карап тотудан тыш, Россия Федерациясе Торак кодексының 110 маддәсенең 3 бүлеге һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 маддәсе таләпләрен бозуларны бетерү турында контрольдә тотучы орган тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең торак-төзелеш кооперативы тарафыннан үтәлү срогы чыгу;

2) Башкарма комитетка киләчәктә күп фатирлы йортны карап тотудан тыш, Россия Федерациясе Торак кодексының 110 маддәсенең 3 бүлеге һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 маддәсе таләпләрен бозу фактлары турында гражданнарның, юридик затларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, шулай ук системадан мәгълүмат керү;

3) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе.

5.6.8. Планлы һәм планнан тыш тикшерү рәвешендәге административ процедураны үткәрү тәртибе административ регламентның 3.3 пунктында билгеләнгән.

5.6.9. Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып тикшерү Акты тора.

Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан билгеләнгән срокта ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмә үтәлмәгән очракта, шулай ук әлеге кимчелекләр торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә реаль куркыныч тудырган очракта, торак-төзелеш кооперативы тарафыннан тиешле кимчелеклр бетерелгәнгә кадәр, Бүлек башлыгы торак-төзелеш кооперативының яңа әгъзаларын җәлеп итү буенча торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген туктату турында күрсәтмә чыгарырга мөмкин. Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Бүлек башлыгы чыгарган күрсәтмә үтәлмәгән очракта, Башкарма комитет әлеге кооперативны ликвидацияләү турында таләп белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## 6 бүлек. Дәүләт функциясен үтәүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

6.1. Бүлек белгечләре тарафыннан Административ регламент һәм дәүләт функциясен үтәүгә карата таләпләрне билгели торган хокукый актлар нигезләмәләренең үтәлешен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.2. Дәүләт функциясе үтәлешенә агымдагы контроль Бүлек белгечләренең эш итүләренә (эш итмәүләренә) һәм алар тарафыннан кабул ителә торган карарларга планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Планнан тыш тикшерүләр Бүлек белгечләренең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирү турында Башкарма комитетка кергән мөрәҗәгатьләрне карап тикшергәндә үткәрелә.

3.3. Контроль нәтиҗәләре буенча гаепле вазыйфаи затларны җаваплылыкка тарту Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 7 бүлек. Өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле бүлегенең, шулай ук вазыйфаи затларның, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

7.1. Бүлек белгечләренең эш итүләренә (эш итмәүләренә) һәм дәүләт функциясен үтәгәндә кабул ителгән карарларына кызыксынган зат тарафыннан язма рәвештә яки электрон документ формасында шикаять җибәрү юлы белән, шулай ук телдән (шәхси кабул иткәндә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирелергә мөмкин.

Гариза бирүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогын бозу;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең башка норматив хокукый актларында каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәт күрсәтүне туктату нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең башка норматив хокукый актларында каралмаган очракта, дәүләт хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

Язма рәвештә җибәрелгән шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган дәүләт функциясен үтәүче органның, дәүләт функциясен үтәүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), яшәү урынының адресы, гариза бирүченең исеме, урнашу урыны, юридик затларны теркәү турында мәгълүмат, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) Бүлекнең, Бүлекнең вазыйфаи затының шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүматлар;

4) Бүлекнең, Бүлекнең вазыйфаи затының карары һәм эш итүе (эш итмәве) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре һәм гариза бирүчегә аның хокуклары, ирекләре һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган, аларны тормышка ашыруга каршылыклар булдырылган яисә законсыз рәвештә нинди дә булса бурыч йөкләнгән дип санау өчен нигезле хәлләр;

5) гариза бирүче хәбәр итәргә кирәк дип саный торган башка мәгълүматлар.

Кирәк булган очракта, гариза бирүче үзенең дәлилләрен раслау өчен шикаятькә (дәгъвага) документлар һәм материаллар яки аларның күчермәләрен терки.

7.2. Шикаятьтә мөрәҗәгать җибәргән гражданның фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта (электрон) адресы күрсәтелмәгән очракта, шикаять буенча җавап бирелми.

Суд карарыннан риза булмыйча бирелгән шикаять, теркәлгән көннән башлап җиде көн эчендә, әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, шикаять җибәргән гражданга кире кайтрыла.

Шикаять тексты укырлык булмаган очракта, шикаятькә җавап бирелми һәм карап тикшерү өчен аларның компетенциясе нигезендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаять теркәлгән көннән соң җиде көн эчендә гражданга хәбәр ителә.

3.3. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез булып гариза бирүче тарафыннан язма рәвештә кәгазьдә, электрон формада яисә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә шикаять бирү тора.

Шикаять почта аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук Бүлекнең вазыйфаи затлары тарафыннан гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә бирелергә мөмкин.

4.4. Дәүләт функциясен үтәгәндә Бүлек хезмәткәрләре тарафыннан кабул ителгән карарларга, аларның эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан карап тикшерелә.

1.5. Кызыксынган зат түбәндәге мәсьәләләр буенча мәгълүмат алырга хокуклы:

1) Эш кәгазьләрен алып бару идәрәсе системасында шикаять теркәлгән керү номеры турында;

2) шикаять эчтәлегенә карата куела торган таләпләр (дәгъвалар) турында;

3) дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат урнаштыру урыны турында.

7.6. Кызыксынган зат шикаятьне аның буенча карар чыгарылганчы кире алырга хокуклы.

7.7. Башкарма комитетка кергән шикаять 59-ФЗ санлы Федераль законның 12 маддәсендә каралган срокларда карап тикшерелә.

7.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Бүлек башлыгы тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне нигезле дип, ә эш итүләрне (эш итмәүләрне), карарларны нигесез дип тану турында һәм кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чараларны билгели;

2) сәбәпләрен нигезләп, шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту турында.

7.9. Карар кабул ителгән көненнән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, кызыксынган затка язма рәвештә һәм кызыксынган затның теләге буенча электрон формада, шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

7.10. Шикаятьләрне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта,

шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге Регламентның 3.9.7 пунктында күрсәтелгән җавапта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1.1 бүлегендә каралган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

Кызыксынган затлар Башкарма комитетның, аның дәүләт функциясен үтәүче хезмәткәрләренең дәүләт функциясен үтәү барышында кабул иткән карарларына, эш итүләренә яки эш итмәүләренә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 1 нче кушымта

«Күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру» дәүләт функциясен үтәү буенча блок-схема




Тикшерүләр үткәрүнең анықланган планын Прокуратурага җибәрү
Тикшерүләр үткәрүнең Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан расланган планын Прокуратурага җибәрү
Тикшерүләрнең еллык планын http://nabchelny.ru сайтында урнаштыру
Кимчелекләр ачыкланды
Прокурор чаралары күрү өчен Прокуратурага җибәрү
Кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмә бирү
Гаепле затны җаваплылыкка тарту
Нигезләр булган очракта, төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне туктату турында гариза белән яки төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затны ликвидацияләү турында гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итү
Кимчелекләр ачыкланды
Юридик затлар белән үзара бәйләнешсез гамәлгә ашырыла торган контроль чараларын оештыру һәм үткәрү
Төзүче, ТТК эшчәнлеген тикшерү турында мәгълүматны һәм законнар белән билгеләнгән башка таләпләрне http://nabchelny.ru сайтында һәм торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында https://наш.дом.рф урнаштыру

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Төзүченең кварталлык хисабын тикшерү
акты
№ ______ «____» __________ ел

Төзүченең исеме

Хисап чоры:

(вазыйфа)

(Фамилия, Исеме, Атасының исеме)

түбәндәге юнәлешләр буенча тапшырылган кварталлык хисапны тикшерү үткәрелде:

| Т/с | Тикшерелә торган мәсьәләләрнең исеме | Тикшерү нәтиҗәсендә билгеләнде |
|---|---|---|
| 1 | Хисапның үз вакытында бирелүе (дата) | |
| 2 | Хисап бирү комплектлылыгы | |
| 3 | Рәсмиләштерү дөреслеге (имзалар, мөһерләр, тегеп кую) | |
| 4 | Кварталлык бухгалтерлык хисабы | |
| | 1 нче кушымта | |
| 5 | Төзүче турында мәгълүматлар | |
| | 2 нче кушымта | |
| 6 | Җиргә хокукны дәүләт теркәвенә алу (яки аренда) | |
| 7 | Төзелешкә рөхсәт булу | |
| 8 | Проект декларациясен бастырып чыгару һәм урнаштыру | |
| 9 | Төзүче тарафыннан өлешләп төзү объектын тапшыру срогы | |
| 10 | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт турында мәгълүмат | |
| | Өлешләп төзүдә катнашу буенча төзелгән килешүләр турында мәгълүмат | |
| 11 | Төзү (булдыру) башланганнан соң төзелгән килешүләрнең гомуми саны | |
| 12 | Хисап чорында төзелгән килешүләрнең саны | |
| 13 | Хисап чорында өзелгән килешүләрнең саны | |
| 14 | Төзелеш башланганнан соң өзелгән килешүләрнең гомуми саны | |
| 15 | Килешүләр буенча йөкләмәләрнең гомуми суммасы | |

| | | |
|---|---|---|
| | Белешмәләр булу | |
| 16 | п. 7- өзелгән килешүләр буенча белешмә (нигезләр) | |
| 17 | п.11- йөкләмәләрнең тиешенчә үтәлмәве турында белешмә | |
| 18 | Үтәлгән килешүләр саны | |
| 19 | Үтәлмәгән килешүләр саны | |
| 20 | Килешүләр буенча үтәлмәгән йөкләмәләрнең гомуми суммасы (млн. сум) | |
| | 3 нче кушымта | |
| 21 | Акчаларны җәлеп итү турында мәгълүматларны анализлау | |
| 22 | Башка чыгымнар (млн.сум) | |
| | Белешмәләр булу | |
| 23 | п. 7- акчаларны сарыф итү юнәлеше һәм проект документларына сылтама күрсәтелгән белешмә | |
| | 4 нче кушымта (нормативларны исәпләү дөреслеге) | |
| 24 | йөкләмәләрнең тәэмин ителеш нормативы (1 дән ким түгел) | |
| 25 | акчаларны максатчан файдалану нормативы (1 дән артык түгел) | |
| 26 | зыян китермәү нормативы (1 дән ким түгел) | |
| | | |
| 27 | Өстәмә мәгълүмат бирү | |
| | Тикшерү нәтиҗәсе | |
| | Хисап (кабул ителде, кабул ителмәде) | |
| | 2004 елның 30 апрелендәге 214-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен бозулар ачыкланды, түбәндәгеләр өлешендә: | |
| п. 6-8 | | |
| | РФ Хөкүмәтенең 2005 елның 27 октябрендәге 645 нче карары таләпләрен бозулар ачыкланды, түбәндәгеләр өлешендә: | |
| п. 1-5, 9-23 | | |
| | | |
| | | |
| | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 21 апрелендәге 233 нче карары таләпләрен бозулар ачыкланды, түбәндәгеләр өлешендә: | |
| п. 24-26 | йөкләмәләрнең тәэмин ителеш нормативы (1 дән ким түгел) | |
| | акчаларны максатчан файдалану нормативы (1 дән артык түгел) | |
| | зыян китермәү нормативы (1 дән ким түгел) | |

Финанс базарлары буенча Федераль хезмәтнең 2006 елның 12 гыйнварындагы № 06-2/пз-н санлы приказы белән расланган Методик күрсәтмәләрнең 1.4 пунктын нигезендә, хисап формаларын тутырганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- хисап формаларында күрсәтелгән күрсәткечләрнең мәгънәви эчтәлеген үзгәртергә;
- хисап формаларының билгеләнгән эзлеклеген үзгәртергә яки төшереп калдырырга;
- хисап формасының логик структурасын бозып, бер хисап графасында берничә күрсәткечне чагылдырырга;
- хисап формаларына төзәтүләр кертергә.

Хисапны тикшерде: (имза) ____________________ (Ф.И.А.и.)

<u>Ачыкланган кимчелекләрне бетерүгә күрсәтмә бирелде:</u>

214-ФЗ санлы Федераль закон – 2004 ел ________________________ кадәр

РФ Хөкүмәтенең 645 нче карары – 2005 ел ________________________ кадәр

РФ Хөкүмәтенең 233 нче карары – 2006 ел ________________________ кадәр

<u>Хисапта ачыкланган кимчелекләр бетерелде:</u>

214-ФЗ санлы Федераль закон – 2004 ел ________________________ (әйе яки юк)

РФ Хөкүмәтенең 645 нче карары – 2005 ел ________________________ (әйе яки юк)

РФ Хөкүмәтенең 233 нче карары – 2006 ел ________________________ (әйе яки юк)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Төзүче тарафыннан торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында мәгълүмат ачуга карата таләпләр үтәлешен тикшерү
А К Т Ы
№ __ «____» __________20___ ел

Төзүче:____________________
(төзүченең исеме)
Урнаштыру: ____________________
(ИНТЕРНЕТ челтәрендәге адрес)

| Т/с | 214-ФЗ санлы Федераль закон таләпләре нигезендә төзүче тарафыннан мәгълүмат ачу һәм урнаштыру | 214-ФЗ санлы Федераль законның пункты | Тикшерү нәтиҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1. | 214-ФЗ санлы Федераль законның 20 маддәсенең 1 бүлегенең 4 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр * | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 1 пункты | |
| 2. | Төзелешкә рөхсәт (һәр объект буенча) * | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 2 пункты | |
| 3. | Мондый экспертиза үткәрү федераль законда билгеләнгән булса, проект документларына экспертиза бәяләмәсе (һәр объект буенча) | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 2 пункты | |
| 4. | Төзүченең жир участогына хокукларын раслаучы документлар (һәр объект буенча) | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 2 пункты | |
| 5. | Проект декларациясе (һәр объект буенча) | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 3 пункты | |
| 6. | Төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә (һәр объект буенча) | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 4 пункты | |
| 7. | Өлешләп төзүдә катнашу килешүенең проекты яки күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү өчен төзүче тарафыннан файдаланыла торган мондый килешүләрнең проектлары (һәр объект буенча) | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 5 пункты | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | Катнашучыларның акчаларын эскроу счетларында урнаштырган очракта, 214-ФЗ санлы Федераль законның 15.4 һәм 15.5 маддәләре таләпләре нигезендә өлешләп төзүдә катнашу килешүе буенча мондый акчаларны җәлеп итү шартлары (һәр объект буенча) | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 6 пункты | |
| 9. | Төзүченең еллык бухгалтерлык (финанс) хисабына аудитор бәяләмәсе | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 7 пункты | |
| 10. | Арадаш бухгалтерлык (финанс) хисабы | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 7 пункты | |
| 11. | Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, төзүче тарафыннан төзелә (булдырыла) торган күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзүнең (булдыруның) агымдагы торышын чагылдыручы фоторәсемнәр | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 8 пункты | |
| 12. | Җир участогының шәһәр төзелеше планы (һәр объект буенча) * | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 9 пункты | |
| 13. | Капиталь төзелеш объектын, подъездларны һәм аңа керү урыннарын, ачык сервитутларның гамәлдә булу зоналары чикләрен, археологик мирас объектларын урнаштыру урыннарын билгеләп, җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыруны оештыру схемасы (һәр объект буенча) | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 10 пункты | |
| 14. | Төзүченең үз акчалары күләменең һәм финанс тотрыклылыгы нормативларының исәбе турында мәгълүматны үз эченә алган документ | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 11 пункты | |
| 15. | «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә банкротлык эшендә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында мәгълүматлар | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 12 пункты | |
| 16. | Шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә җибәрелгән капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү башлау турында хәбәр (һәр объект буенча) | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 13 пункты | |
| 17. | Мондый счет номерын, вәкаләтле банк һәм аның идентификаторларын (салым түләүченең идентификация номерын, төп дәүләт теркәү номерын) күрсәтеп, төзүченең исәп-хисап счетын ачу турында яки ябу турында мәгълүматлар | 3.1 маддәнең 2 бүлегенең 14 пункты | |
| 12. | Төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә, 20 һәм 21 маддәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмәне торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру датасы | 3.1 маддәнең 3 бүлеге | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13. | 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсендәге 2 бүлекнең 8 пунктында күрсәтелгән фоторәсемнәрне урнаштыруның периодик рәвештә кабатлануы | 3.1 маддәнең 3 бүлеге | |
| 14. | 214-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2 бүлегендә күрсәтелгән документларга үзгәрешләрне урнаштыру датасы | 3.1 маддәнең 4 бүлеге | |

*23.3 маддәнең 6.3 бүлегендә каралган мәгълүматны торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыруның техник мөмкинлеге тәэмин ителгәнче, күрсәтелгән мәгълүмат төзүче тарафыннан урнаштырыла

Нәтиҗәләр: 1. ……..
2. ……..

Вазыйфа ____________ /Ф.И.А.и./

Вазыйфа ____________ /Ф.И.А.и./

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозуларны бетерү турында
күрсәтмә

«__» ________

______________________ (үткәрү урыны) № ___________

Төзүченең кварталлык хисабын тикшерү акты нигезендә «__» ________________________
___________________________________________________________________________,
(оешманың, органның, юридик затның исеме)

«Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсенең 2 бүлегенә, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күп фатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ санлы Законына, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Бүлек башлыгы _____________ (Ф.И.А.и.) йөзендә, күрсәтмә бирә

___________________________________________________________________________
(күрсәтмә бирелә торган затның исеме)

«__» ___________ кадәр срокта:

1) кимчелекләрне бетерергә:

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________;
(күрсәтмәнең эчтәлеге, күрсәтмә чыгару нигезе)

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлегенә күрсәтмәнең үтәлешен раслаучы документларны тапшырырга.

Вазыйфаи зат, юридик зат әлеге күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 маддәсенең 4 бүлегендә билгеләнгән административ җаваплылыкка тартылырга тиеш.

Күрсәтмәгә күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү турындагы, шулай ук арбитраж судларында суд эшчәнлеге турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда шикаять бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү әлеге күрсәтмә үтәлешен туктатмый.

Вазыйфаи затның имзасы

________________ ________________ ______________________________
(вазыйфа) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Күрсәтмә алынды ___________________________________________________________
(тикшерүче затның фамилиясе, инициаллары, вазыйфасы, дата, имзасы)